Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-1**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 31 мае

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Устав проекты буенча 2021 елның 28 ноябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең кушымта итеп бирелә торган Уставын кабул итәргә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын;
- Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын кабул итү турында” 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карарын;
- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге XI-1 номерлы карарын;
- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-1 номерлы карарын;
- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге XX-1 номерлы карарын;
- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 1 апрелендәге XLI-1 номерлы карарын;
- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2020 елның 16 октябрендәге III-1 номерлы карарын.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда дәүләт теркәвенә алу өчен юстиция органнарына җибәрергә.

4. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда, “Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар” Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф - челтәрле басма буларак теркәлү: Эл. N ФС77-72471 05.03.2018) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Карар, федераль законнар нигезендә үз көченә керүнең башка срокларына ия булган пунктлардан гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2022елның
31 маендагы
XXII-1 номерлы карары белән
кабул ителде.
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгы

___________ И.Р. Таҗетдинов

# “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ” МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫ

Балык Бистәсе штп.

## I бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 маддә. Муниципаль район һәм аның статусы

1. “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенә “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” гы 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән муниципаль район статусы бирелде.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми аталышы (исеме) – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” (алга таба текст буенча – район), кыскача аталышы – “Балык Бистәсе муниципаль районы”.

### 2 маддә. Районның территориаль корылышы

1. “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге составына түбәндәге муниципаль берәмлекләр керә:

Балык Бистәсе шәһәр җирлеге: Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы (районның административ үзәге);

Анатыш авыл җирлеге: Анатыш авылы (административ үзәк), Шиланка авылы;

Балыклы Чүкәй авыл җирлеге: Балыклы Чүкәй авылы (административ үзәк), Керәшен Казысы авылы, Иске Арыш;

Бәтке авыл җирлеге: Бәтке авылы (административ үзәк), Яншык авылы, Дикое Поле, Кече Укмас авыллары;

Биектау авыл җирлеге: Биектау авылы (административ үзәк), Околоток-Яңасала авылы, Чаллыбаш, Янавыл авыллары, Үрнәк поселогы;

Олы Елга авыл җирлеге: Олы Елга авылы (административ үзәк), Сорочьи Горы авылы, Казаклар авылы, Кама поселогы;

Олы Кульга авыл җирлеге: Олы Кульга авылы (административ үзәк), Олы Осиновка, Дон-Урай, Кече Кульга авыллары;

Зур Мәшләк авыл җирлеге: Зур Мәшләк авылы (административ үзәк), Бикчурай, Югары Мәшләк авыллары;

Олы Өшнәк авыл җирлеге: Олы Өшнәк авылы (административ үзәк), Кече Өшнәк авылы, Югары Өшнәк поселогы;

Олы Солтан авыл җирлеге: Олы Солтан авылы (административ үзәк), Яңа Солтан авылы, Гобәй поселогы;

Казак Чаллысы авыл җирлеге: Казак Чаллысы авылы (административ үзәк), Үри Чаллысы, Бирдебәк, Зур Кадрәк, Иванаево, Кече Кадрәк авыллары;

Корноухово авыл җирлеге: Корноухово авылы (административ үзәк), Зюзино, Шетнев-Чирмешән, Наумово авыллары;

Күгәрчен авыл җирлеге: Күгәрчен авылы (административ үзәк), Зәңгәркүл авылы;

Күки авыл җирлеге: Күки авылы (административ үзәк);

Котлы Бөкәш авыл җирлеге: Котлы Бөкәш авылы (административ үзәк), Мәмли Казак Чаллысы, Сатлыган, Тәберде Чаллысы авыллары;

Масловка авыл җирлеге: Масловка авылы (административ үзәк);

Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге: Югары Тегермәнлек авылы (административ үзәк), Түбән Тегермәнлек авылы;

Яңа Арыш авыл җирлеге: Яңа Арыш авылы (административ үзәк);

Полянка авыл җирлеге: Полянка авылы (административ үзәк);

Рус Әшнәге авыл җирлеге: Рус Әшнәге авылы (административ үзәк);

Троицкий Урай авыл җирлеге: Троицкий Урай авылы (административ үзәк), Гремячка авылы;

Уракчы авыл җирлеге: Уракчы авылы (административ үзәк), Мельничный Пүчинкәсе, Наратлы, Николаевка авыллары;

Шомарбаш авыл җирлеге: Шомарбаш авылы (административ үзәк), Алан-Полян, Таулар, Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авыллары;

Югары Ырга авыл җирлеге: Югары Ырга авылы (административ үзәк), Яңа Ырга авылы;

Шумбут авыл җирлеге: Шумбут авылы (административ үзәк), Кама, Кызылъяр, Степановка, Шестая Речка авыллары;

Шумково авыл җирлеге: Шумково авылы (административ үзәк), Олы Укмас, Әшнәк-Качкалак, Хутор авыллары;

Балтач авыл җирлеге: Балтач авылы (административ үзәк), Ямаш авылы.

2. Районның административ үзәге – Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы.

3. Район чикләре “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында”гы 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән.

4. Район чикләре районның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирлекара характердагы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен шартлар тудыру кирәклеген исәпкә алып, шулай ук районның бөтен территориясендә күрсәтелгән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән.

5. Район чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законы белән гамәлгә ашырыла.

**3 маддә. Районның рәсми символлары**

1. Районның үз рәсми символлары – тарихи, мәдәни һәм башка җирле традицияләрне һәм үзенчәлекләрне чагылдыра торган герб һәм флагы бар.

2. Рәсми символларны тасвирлау, алардан файдалану тәртибе район Советының норматив хокукый актлары белән раслана торган герб турындагы, район флагы турындагы Нигезләмәләр белән билгеләнә.

3. Район гербы сурәте җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының мөһерләрендә, бланкларында һәм башка рәсми документларында, район җирле үзидарә органнары биналарының фасадларында, район Советының утырышлар залында, район Башлыгының, аның урынбасарының һәм район Башкарма комитеты җитәкчесенең эш кабинетларында урнаштырыла. Район гербын рәсми рәвештә кабатлауның башка очраклары район Советы карары белән билгеләнә.

4. Район гербы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узарга тиеш.

**4 маддә. Районда халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга хокукы**

1. Районда җирле үзидарә җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда, турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка формалары ярдәмендә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан гамәлгә ашырыла, шулай ук әлеге Уставта каралган сайлау һәм җирле үзидарәнең башка органнары аша.

2. Гражданнар турыдан-туры һәм җенесенә бәйсез рәвештә үз вәкилләре аша җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, теленә, чыгышына, мөлкәтенә һәм вазыйфаи хәленә, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, җәмәгать берләшмәләренә карауларына карамастан тигез хокукларга ия.

Район территориясендә даими яисә башлыча яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия.

3. Районның һәр кешесе җирле үзидарә органнарына һәм районның җирле үзидарәсе вазыйфаи затларына турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

4. Районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары һәркемгә үз хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагыла торган документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук, әгәр законда башкасы каралмаган булса, гражданнарның районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка тулы һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

5. Районның җирле үзидарә органнары гаммәви мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысул белән халыкка район һәм аның аерым территорияләрен үстерүнең аеруча әһәмиятле мәсьәләләре турында, гомуми файдаланудагы транспорт, торак-коммуналь хуҗалык эше, халыкка төрле хезмәтләр күрсәтүче социаль-мәдәни һәм башка учреждениеләр челтәрен үстерү, социаль ташламалар, 2009 елның 9 февралендәге "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында" 8-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җәмәгать тәртибен саклауның торышы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында даими мәгълүмат бирәләр.

6. Гражданнар, оешмалар, әгәр аларның хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, судта район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә хокуклы.

**5 маддә. Районның җирле үзидарә органнары структурасы**

1. Районның җирле үзидарә органнары структурасына әлеге Устав нигезендә төзелә торган район Советы, район Башлыгы, район Башкарма комитеты, районның Контроль-хисап Палатасы, районның финанс-бюджет Палатасы, районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы керә.

2. Районның җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү турында район Советы

карары күрсәтелгән карарны кабул иткән район Советының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң гына үз көченә керә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан гайре.

### 6 маддә. Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре

1. Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карый:

1) район бюджеты проектын төзү һәм карау, район бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, район бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

2) җирле салымнар һәм район җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

3) районның муниципаль милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;

5) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру һәм аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

6) халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм район чикләрендәге җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

7) район территориясендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу, шулай ук терроризм һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) юк итүдә катнашу;

8) район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыклары телләрен һәм мәдәниятләрен үстерүгә, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, ярдәм итүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм тормышка ашыру, аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыру, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итү, милләтара (этникара) низагларны профилактикалау;

9) район территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм бетерүдә катнашу;

10) муниципаль милиция тарафыннан район территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны оештыру;

11) районның хезмәт күрсәтелә торган административ участогында полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә эш өчен бина бирү;

12) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларны үтәү чорында торак урыны

бирү;

13) җирлекара характердагы әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыру;

14) муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән гайре), муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән гайре), муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга күз-колак булу һәм тәрбияләү, балаларны карап тоту өчен шартлар тудыру, шулай ук үз вәкаләтләре чикләрендә балаларның ялын оештыру чараларын, шул исәптән аларның тормыш һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру;

15) гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган башкарма хакимиятнең аерым территорияләрнең халкын медик-санитар тәэмин итү функциясен гамәлгә ашыручы федераль органы карамагындагы медицина оешмаларында халык медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләр исемлегенә кертелгән җирлекләрнең территорияләреннән гайре);

16) район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерып туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;

17) районны территориаль планлаштыру схемасын раслау, территорияне планлаштыру буенча районның территориаль планлаштыру схемасы нигезендә әзерләнгән документларны раслау, район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару, муниципаль ихтыяҗлар өчен район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлау һәм алу, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруга рөхсәтнамә бирелүе турында хәбәрнамә җибәрү, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамәләр юллау, тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр җибәрү, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә карар, авылара территориядә урнашкан бинаны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры

китерү турында карарлар, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген кире алу турында карар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда үз белдеге белән (рөхсәтсез) төзелгән корылманы сүтүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү;

18) реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау, район территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтнамәләр бирү, мондый рөхсәтнамәләрне гамәлдән чыгару, “Реклама турында” 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә район территориясендә рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен сүтү турында күрсәтмәләр бирү;

19) җирлекләрнең архив фондларын саклауны да кертеп, муниципаль архив төзү һәм аны тоту;

20) район территориясендә җирлекара күмү урыннарын тоту, ритуаль хезмәтләр оештыру;

21) район составына керүче җирлекләрне элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

22) җирлекара китапханәләрдә халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, аларның китапханә фондларын туплау һәм сакланышын тәэмин итү;

23) район составына керүче җирлекләрне ял итүне оештыру хезмәтләре һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

24) район составына керүче авыл җирлекләрендә җирле традицион халык сәнгатен үстерү өчен шартлар тудыру;

25) район милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) саклау;

26) район составына керүче җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен район бюджеты акчалары исәбеннән тигезләү;

27) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм район территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

28) район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

29) район территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

30) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

31) җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү, социаль юнәлешле коммерциягә

карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү, хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык-иреклелек (волонтерлык) буенча ярдәм күрсәтү;

32) район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм гавами спортны үстерү өчен шартлар булдыру, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

33) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

34) Россия Федерациясе су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне дә кертеп;

35) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

36) "Федераль милектә булган су объектларында ясалган ясалма җир кишәрлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 19.07.2011 ел, № 246-ФЗ Федераль закон нигезендә, муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;

37) район чикләрендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру;

38) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан гайре), муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыру;

39) районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

40) "Кадастр эшчәнлеге турында" 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкару һәм территориянең карта-планын раслау.

2. Районның җирле үзидарә органнары район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә район бюджетыннан тиешле җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны аларга тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

### 7 маддә. Районның җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

1. Районның җирле үзидарә органнарының түбәндәгеләргә хокуклары бар:

1) муниципаль район музейларын булдыру;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнашу;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни мохтариятләрнең хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

4) муниципаль район территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү;

5) 2008 елның 31 декабренә аларның карамагында булган югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен гамәлгә ашыру;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм итүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

8) “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

9) “Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында” 20.07.2012 ел, № 125-ФЗ Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыру;

10) авылара территориядә урнашкан торак пунктта нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләрне башкару;

11) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне контрольдә тоту;

12) “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында” 23.06.2016 ел, № 182-ФЗ Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

13) инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын үстерүгә, адаптив физик культурага һәм җайлашу спортына ярдәм күрсәтү;

14) “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 07.02.1992 ел, № 2300-1 Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

15) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;

16) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;

17) муниципаль янгын сагы булдыру.

2. Районның җирле үзидарә органнары әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашырга хокуклы (“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 маддәсе нигезендә аларга тапшырылмаган), әгәр дә бу катнашу федераль законнарда каралган булса, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең

җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән аларның компетенциясеннән төшереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне җирле бюджетларның керемнәре хисабына хәл итәргә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән гайре.

**8 маддә. Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булган һәм авыл җирлекләре территорияләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган башка мәсьәләләр.**

1. Районның җирле үзидарә органнары районның авыл җирлекләре территорияләрендә җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә:

1) район составына керүче авыл җирлекләре чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне оештыру (алга таба – авыл җирлекләре) ;

2) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын, юл хәрәкәтен оештыру буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

3) авыл җирлекләрендә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләре;

4) халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

5) терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук авыл җирлекләре чикләрендә терроризм һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу;

6) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүдә катнашу;

7) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, авыл җирлекләре китапханәләренең китапханә фондларын туплау һәм сакланышын тәэмин итү;

8) авыл җирлекләре милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) саклау;

9) җирле традицион халык сәнгатен үстерү өчен шартлар тудыру, авыл җирлекләрендә халык сәнгате кәсепләрен саклап калу, торгызу һәм үстерүдә катнашу;

10) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр

урманнарын, аеруча саклаулы табигать территорияләреннән файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу эшләрен оештыру;

11) авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтнамәләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан гайре), авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә бирү, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында рекомендацияләр бирү, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булуы турында хәбәрнамә юллау (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә), индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булмавы турында хәбәрнамә юллау, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының туры килү-килмәве турында хәбәрнамә юллау, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген кире алу турында карар кабул итү;

12) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча, халыкны һәм авыл җирлекләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) авыл җирлекләре территорияләрендә авария-коткару хезмәтләре һәм (яки) авария-коткару формированиеләрен (берләшмәләрен) төзү, тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

14) авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

15) авыл җирлекләре территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән

файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

16) Россия Федерациясенең су законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, халыкка аларны куллану чикләүләре турында мәгълүмат бирү;

17) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

18) полициянең участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә авыл җирлекләренең хезмәт күрсәтелә торган административ участокларында эшләү өчен бина бирү;

19) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полиция участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфа буенча хезмәткәрләр тарафыннан вазыйфаларын үтәү чорында торак урыннары бирү;

20) “Коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар турында” 12.01.1996 ел, № 7-ФЗ Федераль законның 31.1 һәм 31.3 маддәләрендә билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

21) “Федераль милектә булган су объектларында ясалган ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 19.07.2011 ел, № 246-ФЗ Федераль закон нигезендә, җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;

22) авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру;

23) “Кадастр эшчәнлеге турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә авыл җирлекләре территорияләрендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу;

24) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру.

**9 маддә. Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү**

1. Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

2. Районның җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру өчен әлеге максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә җаваплы.

3. Тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру дәүләт контролендә. Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору шартлары һәм тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә. Район Советы үз вәкаләтләре чикләрендә район җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану очракларын һәм тәртибен аларга

тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләргә хокуклы.

**10 маддә. Районның муниципальара хезмәттәшлек итүдә катнашуы**

1. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы федераль законнар һәм җирле үзидарә турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**11 маддә. Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасындагы үзара мөнәсәбәтләр түбәндәгеләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла:

1) районның социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда районның җирле үзидарә органнарының катнашуы;

2) районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яисә вакытлыча координацияләү (яраштыру), консультатив (мәслихәт бирү), киңәшмә һәм башка эшче органнар булдыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында район Советының закон чыгару инициативасы;

5) кануннарда билгеләнгән башка багланыш рәвешләре.

**12 маддә**. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләүне, муниципаль хезмәт үтү шартларын һәм тәртибен дә кертеп, районда муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел, № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы, әлеге Устав һәм районның муниципаль хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

## II бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛУЫ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУ РӘВЕШЛӘРЕ

**13 маддә. Җирле үзидарәнең халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашырылуы һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу рәвешләре**

1. Район халкы турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыра һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда түбәндәге рәвешләрдә катнаша:

1) җирле референдум;

2) чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;

3) гражданнарның хокукый инициативасы;
4) гавами тыңлаулар, җәмәгатьчелек фикер алышулары;
5) гражданнар җыелышлары;
6) гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);
7) гражданнардан сораштыру;
8) җирле әһәмияттәге иң мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы;
9) җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгате;
10) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар.

**14 маддә. Җирле референдум**

1. Җирле референдум федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тудан-туры район халкы тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында үткәрелә.
2. Җирле референдум 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон һәм "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, районның бөтен территориясендә үткәрелә.
3. Җирле референдумда яшәү урыны район чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала. Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә һәм законда билгеләнгән тәртиптә район территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары Россия Федерациясе гражданнары кебек үк җирле референдумда катнаша.
4. Җирле референдум билгеләү турындагы карар район Советы тарафыннан түбәндәгеләр инициативасы нигезендә кабул ителә:
1) җирле референдумда катнашу хокукына ия гражданнар;
2) уставлары федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән һәм сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашуны күздә тоткан сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр;
3) Район Советы һәм район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан бергә тәкъдим ителгән инициатива.
5. Гражданнар, сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр инициативасы буенча җирле референдум билгеләү шарты булып, әлеге инициативаны хуплау өчен имза җыю тора, ул район территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санының биш процентын тәшкил итәргә тиеш, әмма имзалар саны 25тән дә ким була алмый.
6. Референдум үткәрү инициативасы район Советы һәм район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан район Советы карары һәм район Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән рәсмиләштерелә.
Күрсәтелгән инициативаны тәкъдим итү тәртибе район Советының норматив

хокукый акты белән тәгаенләнә.

7. Район Советы җирле референдумны район Советына җирле референдум билгеләнә торган документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгели,

8. Референдумда тавыш бирүне үткәрү датасы билгеләнгән көнгә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча район Советы карары буенча аны дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына билгеләнгән сайлауларда тавыш бирү көне яисә башка билгеләнгән референдумда тавыш бирү көне белән бергә үткәрү максатларында соңрак вакытка күчерелергә мөмкин (әмма 90 көннән дә артыкка түгел).

9. Референдум билгеләү, шулай ук референдумда тавыш бирү көнен күчерү турындагы карар әлеге маддәнең 8 пункты нигезендә гаммәви мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә кабул ителгән көннән биш көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.

10. Җирле референдумда кабул ителгән тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

11. Җирле референдумда кабул ителгән карар район территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм дәүләт хакимиятенең нинди дә булса органнары, аларның вазыйфаи затлары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

12. Районның җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

13. Җирле референдум үткәрү, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карарга федераль законнар нигезендә гражданнар, җирле үзидарә органнары, прокурор, федераль закон белән вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

**15 маддә. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү чикләрне үзгәртүгә, районны үзгәртүгә халык ризалыгын алу максатларында үткәрелә.

2. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән очракларда районның бөтен территориясендә яки аның территориясенең бер өлешендә үткәрелә.

3. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү район Советы тарафыннан билгеләнә һәм "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль закон һәм "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ

Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

4. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, анда районның яки аның бер өлешенең сайлау хокукына ия халкының яртысыннан артыгы катнашса, узган дип санала. Халыкның район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп коруга ризалыгы күрсәтелгән район чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору өчен районның яки аның бер өлешенең тавыш бирүдә катнашкан халкының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, алынган дип санала.

5. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 16 маддә. Гражданнарның хокукый инициативасы

1. Район халкы хокукый инициатива белән әлеге Устав һәм район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә чыгыш ясарга хокуклы.

2. Сайлау хокукына ия булган район халкы санының 3 проценттан артмаган өлешен тәшкил итүче гражданнар төркеме хокукый инициатива белән чыгыш ясарга мөмкин.

3. Хокукый инициативаны гамәлгә ашыру максатларында район халкы хокуклы:

- яшәү (эш) урыны буенча гражданнар җыелышларын һәм хокукый инициативасы турында фикер алышу һәм тәкъдим итү буенча башка күмәк чаралар оештырырга һәм үткәрергә;
- хокукый инициативаны тәкъдим итүне хуплау өчен имзалар җыю буенча инициатива төркемнәре булдырырга;
- район халкыннан имзалар җыярга һәм законнарга каршы килми торган юллар белән тәкъдим ителгән хокукый инициативаны хуплау өчен агитация алып барырга.

4. Районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары район халкына хокукый инициативаны гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә бурычлы.

5. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты район Советының ачык утырышында, район Башлыгы яки Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан Уставта билгеләнгән үз компетенцияләре нигезендә, ул кертелгәннән соң өч ай эчендә мәҗбүри каралырга тиеш..

6. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проектын карау процедурасы район Советы Регламенты, район Башлыгының, район Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән тәгаенләнә.

## 17 маддә. Гавами тыңлаулар, җәмәгатьчелек фикер алышулары

1. Район халкы катнашында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектлары турында фикер алышу өчен район Советы, район Башлыгы тарафыннан гавами тыңлаулар үткәрелергә мөмкин.

2. Гавами тыңлаулар халык, район Советы яки район Башлыгы инициативасы

белән үткәрелә. Халык яки район Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар район Советы тарафыннан билгеләнә, ә район Башлыгыныкы – район Башлыгы тарафыннан.

3. Гавами тыңлауларга чыгарылырга тиеш:

1) район Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында аларның нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендәге үзгәрешләр кертелә торган очраклардан гайре;

2) район бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты;

4) муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турында мәсьәләләр, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсе нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртү өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән муниципаль берәмлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан гайре.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү турындагы карар тиешле орган яисә районның вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проектын караганчыга кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш, әгәр законда башкасы каралмаган булса.

5. Үткәрү вакыты һәм урыны күрсәтелгән гавами тыңлаулар үткәрү турында карар һәм гавами тыңлауларга чыгарылучы тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, әгәр законда башкасы каралмаган булса.

6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында карар басылып чыккан көннән алып һәм аларны үткәрү көненә кадәр район халкы район Башлыгына тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма рәвештә тәкъдимнәр һәм искәртүләр җибәрергә хокуклы, шул исәптән гавами тыңлауларга чыгарылучы муниципаль норматив хокукый акт проектына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр дә. Район Башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәртүләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм искәртүләр гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерелә.

7. Гавами тыңлаулар муниципаль норматив хокукый акт проекты каралганчыга кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча үткәрелә, әгәр законда башкасы каралмаган булса. Гавами тыңлаулар белгечләр, экспертлар, кызыксынган затлар катнашында үткәрелә. Гавами тыңлауларда районның һәр кешесе катнашырга хокуклы.

8. Гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча компетенцияләренә ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү кертелгән җирле үзидарә органнары һәм районның вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле тәкъдимнәр кабул ителә.

9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча рәсми басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиеш, әгәр законда

башкасы каралмаган булса.

10. Әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе район Уставы һәм район Советының норматив хокукый актлары белән тәгаенләнә.

11. Әлеге маддәдә күрсәтелгән сроклар гамәлдә булган законнар белән гавами тыңлаулар өчен каралган башка сроклар билгеләнмәгән очракта кулланыла.

12. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияләрне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануга рөхсәтнамә бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтнамә бирү турындагы карар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда җир биләмәләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану рөхсәт ителгән бер төрне мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар яисә җәмәгатьчелек фикер алышулары үткәрелә.

## 18 маддә. Гражданнар җыелышы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, халыкка җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, район территориясенең бер өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру һәм инициативалы проектларны кертү мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен гражданнар җыелышлары үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыелышлары микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар, районның торак пунктлары буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыелышы халык, район Советы, район Башлыгы инициативасы белән үткәрелә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда.

3. Район Советы яки район Башлыгы инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыелышы тиндәшле рәвештә район Советы яки район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыелышы район Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, халык саныннан кимендә 10 процент тәшкил иткән тиндәшле территориядә яшәүче һәм җыелышта катнашырга хокуклы гражданнар төркеменең, бу территорияләрдә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренең язма тәкъдиме буенча билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимдә тикшерүгә чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеге, җыелышны үткәрү вакыты һәм урыны булырга тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланырга тиеш, ә җыелышны үткәрү инициативасы белән бер төркем гражданнар мөрәҗәгать итсә, аларның

һәркайсының фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урыны адресын күрсәтеп.

Район Советы гражданнар җыелышын үткәрү турында кертелгән тәкъдимне якын арада үтәчәк утырышында карый.

Район Советы гражданнар җыелышын аның максатка яраклы булмавын сылтау итеп үткәрүне кире кагарга хаклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны һәм фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләргә җыелыш үткәреләсе көнгә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча моның өчен гаммәви мәгълүмат чаралары, почта хәбәрнамәләре, һәр фатирны аерым-аерым йөреп чыгу, белдерүләр һәм башка мөмкин булган чаралар кулланып хәбәр итәләр. Гражданнар җыелышына әзерлекне һәм үткәрүне район Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия гражданнар катнашырга хаклы. Җыелышта катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм булу урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын муниципаль сайлауларны үткәргәндә файдаланыла торган теркәү исәбенә алу мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.

Гражданнар җыелышында инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

Инициатив проектларны кертү максаты белән мәсьәләләрне карау һәм фикер алышу өчен гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

Гражданнар җыелышы, җыелышта катнашырга хокуклы гражданнар санынннан кимендә өчтән бер өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итә, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле затларны сайлый ала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан мөрәҗәгатьләрдә булган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә кертелгәнлектән мәҗбүри каралырга тиеш һәм язма рәвештә җавап җибәрү белән.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, әлеге Устав, район Советының норматив хокукый акты һәм

территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышы нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 19 маддә. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм район халкының фикерен ачыклау зарурилыгы очрагында үткәрелә. Район территориясенең бер өлешендә яшәүче халык арасыннан гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышын чакыру авыр булган очракларда үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышларын) билгеләү һәм үткәрү, делегатлар сайлау тәртибе әлеге Устав һәм (яки) район Советының норматив хокукый акты белән тәгаенләнә.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышының вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, район Советы, район Башлыгы инициативасы белән үткәрелә. Район Советы яки район Башлыгы инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар конференциясе тиңдәшле рәвештә район Советы яки район Башлыгы тарафыннан тәгаенләнә. Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) район Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), әгәр анда сайланган делегатларның яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала. Конференция (делегатлар җыелышы) карарлары конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6. Гражданнар (делегатлар җыелышлары) конференциясе нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 20 маддә. Гражданнардан сораштыру

1. Гражданнардан сораштыру район территориясендә яки район территориясенең бер өлешендә халыкның фикерен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә исәпкә алу өчен үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим (киңәш) итү сыйфатына ия.

2. Гражданнардан сораштыруда сайлау хокукына ия район халкы катнаша ала. Инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнардан сораштыруда инициатив проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек яки аның бер өлешендәге уналты яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

3. Гражданнардан сораштыру түбәндәгеләр инициативасы буенча үткәрелә:

1) район Советы яки район Башлыгы – җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары – район җирләренең максатчан билгеләнешен республика һәм төбәкара әһәмияттәге объектлар өчен

үзгәртү турында карар кабул иткәндә гражданнарның фикерен исәпкә алу өчен;

3) инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнардан сораштыруда инициатив проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы яки аның бер өлешендәге уналты яшькә җиткән яшәүчеләр – әлеге инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.

4. Гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе әлеге Устав һәм район Советының норматив хокукый акты белән Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.

5. Гражданнар арасында сораштыру билгеләү турында карар район Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү турындагы район Советы карарында тәгаенләнә:

1) сораштыру үткәрүнең датасы һәм сроклары;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) тәгъбирләнеше;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең рәвеше;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру үткәрү очрагында сораштыруда катнашучыларны таныклау тәртибе.

7. Гражданнардан сораштыруны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чараларны финанслау гамәлгә ашырыла:

1) район бюджеты акчалары хисабына – район җирле үзидарә органнары яки муниципаль район халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә.

8. Сораштыру нәтиҗәләре аны үткәргәннән соң бер ай эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән районның һәр кешесе таныша ала. Сораштыру нәтиҗәләре районның җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул иткәндә исәпкә алынырга тиеш.

## 21 маддә. Җирле әһәмияттәге иң мөһим мәсьәләләр буенча халык (-ның) фикер алышуы

1. Муниципаль норматив хокукый актлар һәм җирле әһәмияттәге башка мөһим мәсьәләләр проектларын халык фикер алышуына чыгару турында карар район Советы тарафыннан үз инициативасы буенча яки район Советы билгеләгән тәртиптә тиндәшле территориядә яшәүче гражданнар таләбе буенча кабул ителә.

2. Муниципаль норматив хокукый акт проекты тексты һәм халык фикер алышуына чыгарылучы мәсьәләләр буенча башка материаллар аларны халык фикер алышуына чыгару турында карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча

гаммәви мәгълүмат чараларында басылып чыга, район халкына таратыла, халык таныша алырлык урыннарга урнаштырыла, башка ысуллар белән халыкка җиткерелә.

3. Халык фикер алышуына сорауны чыгару белән бер үк вакытта район Советы фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәр һәм искәртүләрне карау буенча эшне оештыруның срогын һәм тәртибен тәгаенли, күрсәтелгән максат өчен махсус комиссия булдыра.

4. Район Советы фикер алышу өчен чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка иң мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышуны тәэмин итә, моның өчен зарур булган шартларны булдыра.

5. Халык фикер алышуына чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәртүләр район Советына юллана.

6. Муниципаль норматив хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка мөһим мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәртүләр район Советы тарафыннан карала.

7. Халык фикер алышуы нәтиҗәләре турында халыкка бер ай вакыт эчендә хәбәр ителә.

**22 маддә. Җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгате**

1. Гражданнар җирле үзидарә органнарына индивидуаль рәвештә һәм күмәк мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 02.05.2006 ел, № 59-ФЗ Федераль законда һәм "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 12.05.2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарәнең урындагы кешеләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

**23 маддә. Район халкы тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм аны гамәлгә ашыруда катнашуының башка рәвешләре**

1. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге Уставта каралган җирле үзидарә халкы тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашырылу рәвешләре һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы белән беррәттән гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка рәвешләрдә катнашырга хокуклы.

2. Район халкының турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыруы һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы законлылык, ирекле принципларына нигезләнә.

Җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарәсенең урындагы

кешеләре халыкка җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруда һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуында ярдәм итәргә тиеш.

## III бүлек. РАЙОН СОВЕТЫ

### 24 маддә. Район Советы – район җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы

1. Район Советы җирле үзидарәнең сайланулы даими эшләүче, коллегиаль вәкиллекле органы булып тора.

2. Район Советының рәсми аталышы – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Советы. Район Советының кыскартылган аталышы – Балык Бистәсе муниципаль район Советы.

3. Район Советының вәкаләтләре вакыты – 5 ел.

4. Район Советы район халкына хисапта һәм контролендә.

5. Район Советының үз аталышы (исеме) язылган мөһере, район гербы сурәте төшерелгән бланклары бар.

6. Район Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

7. Район Советы юридик зат хокукына ия.

### 25 маддә. Район Советы составы

1. Район Советы 54 депутаттан тора.

2. Район Советы аның составына билгеләнгән санынннан кимендә өчтән ике депутатны сайлаганда тулы хокуклы.

### 26 маддә. Район Советы депутатларын сайлау тәртибе

1. Район советы составына район составына керүче авыл җирлекләре башлыклары һәм әлеге җирлекләрнең вәкиллекле органнарының җирлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан үз составыннан җирлекнең халкы санына бәйсез рәвештә һәр җирлектән бер вәкил итеп тигез вәкиллек нормасы нигезендә сайланган депутатлары керә.

Район составына керүче бер җирлекнең вәкиллек нормасы район Советының билгеләнгән санынннан өчтән береннән артмаска тиеш.

2. Җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан сайланучы район Советы депутаты тиндәшле җирлекнең яңа чакырылыш вәкиллекле органының тулы хокуклы составындагы беренче утырышыннан соң бер айдан да соңга калмыйча сайланырга тиеш, шул исәптән узган чакырылыш әлеге орган вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта да.

3. Җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан район Советы депутатын сайлау яшерен тавыш бирү юлы белән башкарыла һәм күрсәтелгән орган карары белән рәсмиләштерелә.

4. Җирлек башлыгын сайлау һәм җирлекнең вәкиллекле органы депутатын

район Советы депутаты итеп сайлау турында җирлекнең вәкиллекле органы карары өч көн эчендә район Советына җибәрелә.

### 26.1 маддә. Район Советында фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре

1. Сәяси фиркаләр (аларның төбәк бүлекчәләре яки башка структур бүлекчәләре) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге составында сайланган район Советы депутатлары депутатлар берләшмәләренә (фракциядә) керәләр (алга таба – фракция), әлеге маддәнең 6 өлешендә каралган очрактан гайре. Фракция кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган барлык депутатларны (депутатны) үз эченә ала. Фракцияләргә шулай ук бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар да һәм әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка (аның төбәк бүлекчәләре яки башка структур бүлекчәләре) кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар (депутат) керә ала.

2. Фракцияләрнең эшчәнлек тәртибе “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм район Советы Регламенты белән тәгаенләнә.

3. Фракциянең тулы аталышы (исеме) сәяси фирка уставында күрсәтелгән исем, аның кандидатлар исемлеге составында тиңдәшле депутатлар сайланган. Фракция фракция турындагы нигезләмәдә билгеләнгән кыскача аталышка (исемгә) хокуклы, ул аның тулы исеменә туры килергә тиеш.

4. Фракцияләр район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителеп теркәлергә тиешләр.

Яңа теркәлгән фракция турында мәгълүматлар, шулай ук әлеге фракциягә керүче депутатлар (депутат) турында мәгълүматлар теркәлгәннән соң район Советының беренче утырышта игълан ителә.

5. Фракциянең эчке эшчәнлеге фракция тарафыннан аның оештыру җыелышында раслана торган нигезләмә нигезендә кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган депутатларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән фракция турындагы Нигезләмә нигезендә аның тарафыннан мөстәкыйль рәвештә оештырыла.

6. Сәяси фирка эшчәнлеге туктатылган, аның бетерелүе яки үзгәртеп корылуы белән бәйле рәвештә, аның фракциясе эшчәнлеге район Советында, шулай ук депутатларның әлеге фракциядә әгъзалыгы юридик затларның Бердәм дәүләт реестрына тиешле язма кертелгән көннән туктатыла.

7. Сәяси фирка тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутат әлеге маддәнең 1 өлеше нигезендә торган фракциядән чыгарга хокуклы түгел. Күрсәтелгән депутат үзе сайланган кандидатлар исемлеге составында сәяси фирканең генә әгъзасы була ала.

8. Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат яисә әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм фракциягә керүче депутат фракциясенә кергән сәяси фирка әгъзасы гына булырга мөмкин.

9. Әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка кандидатлары исемлеге

составында сайланган һәм район Советында үз фракциясе булган сәяси фиркагә кергән депутат әлеге фракциягә керә һәм аннан чыгарга хаклы түгел.

10. Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат аннан хәбәр итү тәртибендә чыгарга хокуклы.

Депутатның фракциядә әгъза булуын туктату турында мәгълүмат әгъза булудан туктаганнан соң узучы беренче Совет утырышында игълан ителә.

11. Әлеге маддәнең 7-9 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәмәү депутат вәкаләтләрен туктатуга китерә.

12. Район Советы фракциясенә керүче кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатларның (депутатның) вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта әлеге исемлек составында сайланган депутатларның (депутатның) булмавына китерсә, район Советында күрсәтелгән фракция эшчәнлеге туктатыла. Шуның белән бер үк вакытта мондый фракциядә аның составына керүче бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатларның әгъзалыгы туктатыла, әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатларның да.

13. Фракция эшчәнлеген туктату турында мәгълүмат әлеге маддәнең 6, 12 өлешләре нигезендә туктаганнан соң узучы беренче Совет утырышында игълан ителә.

14. Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган фракцияләргә кермәгән депутатлар һәм сәяси фирка (аның төбәк бүлекчәләре яки башка структур бүлекчәләре) кандидатлары исемлеге составында сайланган әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән фракцияләргә кермәгән депутатлар фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре төзи ала. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре фирка, территориаль, һөнәри яки башка билге буенча формалаша. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе район Советы регламенты белән билгеләнә.

15. Барлык депутат мандатлары да бер мандатлы һәм (яки) күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар тарафыннан биләнә торган район Советы депутатлары фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре төзи ала. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре фирка, территориаль, һөнәри яки башка билге буенча формалаша. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе район Советы Регламенты белән билгеләнә.

16. Район Советы депутатлары бер депутат берләшмәсендә генә торырга хокуклы.

### 27 маддә. Район Советы депутаты статусы

1. Әлеге Уставның 26 маддәсенең 1 өлеше нигезендә район составына керүче авыл җирлекләре башлыкларыннан һәм күрсәтелгән җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан торган район Советы депутаты вәкаләтләре район составына керүче авыл җирлеге башлыгы вазыйфасына керешкәннән соң башлана яки әлеге җирлекнең вәкиллекле органы депутаты район Советы депутаты итеп сайланганнан соң һәм яңа сайланган җирлек башлыгы вазыйфасына керешкәннән соң туктатыла яисә әлеге җирлектән район Советы составына депутат сайлау турындагы карар үз көченә кергән көннән соң.

2. Район Советы депутаты үз эшчәнлеген депутат статусы һәм район Советы

Регламенты нигезендә башкара.

3. Район Советы депутаты түләүсез эшли, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча эш урыны һәм хезмәт вазыйфаларын башкару белән бергә алып бара, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан гайре.

4. Район Советы депутаты 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ санлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белен билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны (бурычлар, йөкләмәләрне) башкарыйрга тиеш. Район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла шул очракта, әгәр чикләүләр, тыюлар, бурыч-йөкләмәләр үтәлмәсә, ә алар 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән, әгәр “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

5. Район Советы депутаты үз вәкаләтләрен законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары нигезендә каршылыксыз гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

6. Район Советы депутаты район Советы тарафыннан расланган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә, шул исәптән депутатның түбәндәге вазыйфаларын да тотарга тиеш:

1) башка җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусын шәхсән яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә файдаланмаска;

2) депутат вазыйфаларын объектив башкаруда шик тудырырлык тәртиптән тыелырга, шулай ук Совет абруена яки үзенең репутациясенә зыян китерергә сәләтле низаглы ситуацияләрдән котылырга;

3) мәнфәгатьләр каршылыгы (район Советы депутатының шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки читләтеп) депутат вәкаләтләренең тиешле, объектив һәм гадел гамәлгә ашырылуына тәэсир итә яки йогынты ясый ала торган ситуацияләр) барлыкка килү куркынычы булганда, район Советы билгеләгән тәртиптә, бу хакта аңа билгеле булуга ук мәнфәгатьләр конфликты (каршылыгы, низагы) турында яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә, район Советының әлеге мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында карарын үтәргә бурычлы;

4) район Советында билгеләнгән халык алдында (гавами) чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда Федераль закон нигезендә конфиденциаль характердагы мәгълүматларга кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган мәгълүматларны

таратмаска һәм кулланмаска;

6) депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (хак) алмаска (бүләкләр, акчалата бүләк (хак), ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары һәм башка бүләкләүләр).

7. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы район Советы депутаты хокуклы түгел:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерциягә нигезләнмәгән оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке

булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш алып баручы аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

8. Вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы район Советы депутаты граждан, административ яки җинаять эше яки административ хокук бозу эше буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак чыгыш ясый алмый.

Район Советы депутатлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав нигезендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә билгеләнә.

9. Район Советы депутаты тарафыннан коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары буенча Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

10. Әлеге маддәнең 7 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда Татарстан Республикасы Президенты район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки күрсәтелгән затларга карата башка төр җаваплылык чарасын куллану турында гариза (белдерү) белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле район Советына мөрәҗәгать итә яки судка.

11. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән район Советы депутатына, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү дәрәҗәсе алай ук мөһим булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү (искәртү);

2) депутатны вазыйфадан азат итү, район Советында вазыйфа биләүдән мәхрүм итү;

3) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре туктатылганчы, район Советында вазыйфа биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре туктатылганчы, даими нигездә вәкаләтләр башкарудан тыю.

12. Депутатка карата әлеге маддәнең 11 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

13. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла һәм (яки) гаммәви мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә торган тәртиптә бирелә.

**28 маддә. Район Советы депутатының район халкы белән үзара мөнәсәбәте**

1. Район Советы депутаты район халкы, шулай ук район территориясендә урнашкан предприятие, оешма, дәүләт һәм башка органнар коллективлары белән элемтәдә тора.

2. Район Советы депутаты үзе вәкил булып торган җирлек халкы алдында хисап тота, үз эше турында, район Советы эше турында даими мәгълүмат бирә, шулай ук халыкны кабул итә.

3. Район Советы депутаты район халкының законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чаралар күрергә бурычлы, шул исәптән алардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карау, аларда булган мәсьәләләрне дөрес һәм үз вакытында хәл итүгә ярдәм итү.

4. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды территорияләрендә, аларны үткәрү тормыш-көнкүреш объектлары эшчәнлеген бозуга, транспорт һәм социаль инфраструктура, элемтә, җәяүлеләр һәм (яки) транспорт чаралары хәрәкәтенә комачаулык тудыру яки гражданнарның торак урыннарына яки транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә юл куймауга китермәслек шарт белән үткәрелә. Мондый очрашулар турында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны үткәрү датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

5. Район башкарма комитеты депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар билгели, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен тәгаенли.

6. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

7. Депутатның сайлаучылар белән җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган гавами чара формасында сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә үткәрүгә комачаулык итү Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

**29 маддә. Яңа сайланган район Советы эшен оештыру**

1. Яңа чакырылыш район Советы беренче утырышка район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе сайланган көннән 7

көн эчендә җыйнала. Сайлаулардан соң район Советының беренче утырышын район Советының алдагы чакырылышында сайланган район Башлыгы чакыра һәм әзерли, ә ул булмаганда – район Башкарма комитеты җитәкчесе.

2. Сайлаулардан соң район Советының беренче утырышын район Башлыгы сайланганчы яшь ягыннан иң өлкән район Советы депутаты ача һәм алып бара.

### 30 маддә. Район Советы компетенциясе

1. Район Советы компетенциясендә:

1) район Уставын район кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, муниципаль хокукый актлар чыгару;

2) районның рәсми символларын билгеләү;

3) район бюджеты проектын карау, район бюджетын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау, аның үтәлешен контрольдә тоту;

4) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирлекләр бюджетларына Россия Федерациясе Бюджет кодексы, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль районнар бюджетларына күчерелергә тиешле махсус салым режимнарында каралган федераль, региональ һәм җирле салымнар һәм җыемнар, салымнардан керемнәрне күчерү нормативларын билгеләү;

5) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару, аларны түләү буенча ташламалар бирү;

6) районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;

7) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең приоритетлары һәм максатлары белән килештерелгән муниципаль идарәнең һәм районның социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;

8) җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын карау, раслау (хуплау);

9) җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыруны тикшерү;

10) стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башка вәкаләтләр;

11) чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору турында инициативаны тәкъдим итү;

12) җирле референдумны билгеләү;

13) район Башлыгын сайлау;

14) район Башлыгының урынбасарын сайлау;

15) җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, район җирле үзидарәсенең сайланулы органнары әгъзалары, район Советы депутатларына һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

16) район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү, аның отставкасын кабул итү;

17) район Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләренең

чик санын билгеләү;

18) район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен билгеләү, конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

19) районның Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәне раслау, районның Финанс-бюджет палатасы турындагы нигезләмәне һәм районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәне раслау;

20) район сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

21) чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне билгеләү;

22) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Закон чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру;

23) районның муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгеләү, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартларын; читләштерү район Советы тарафыннан килештерелеп яки расланганнан соң башкарыла торган муниципаль милек төрләре исемлеген билгеләү;

24) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләре күрсәтүгә, эшләр башкаруга тарифларны билгеләү турында, федераль законнарда каралган очраклардан гайре;

25) районның муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибен билгеләү;

26) районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

27) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкаруны контрольдә тоту;

28) Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә районның территориаль планлаштыру документларын, башка шәһәр төзелеше документларын раслау;

29) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен җирле финанс һәм матди ресурслар резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибен билгеләү;

30) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү өчен район бюджетыннан кирәкле акчалар бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

31) автоном коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

32) үз гаммәви мәгълүмат чараларын гамәлгә кую;

33) район Уставын һәм район Советы карарларын аңлату;

34) район Советы регламентын һәм үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча бүтән карарлар кабул итү;

35) район Советы Аппараты турында нигезләмәне раслау;

36) район Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

37) билгеләнгән тәртиптә район Контроль-хисап палатасы рәисен һәм әгъзаларын (аудиторларын) билгеләү;

38) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

39) федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль районнарның вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав белән район Советы компетенциясенә кертелгән бүтән вәкаләтләр.

2. Район советы авыл җирлекләренең генераль планнарын һәм Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә авыл җирлекләренең башка шәһәр төзелеше документациясен раслый.

3. Район Советы район Башлыгының, район Башкарма комитеты җитәкчесенең, район Башкарма комитеты һәм район Башлыгына караган башка җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапларын тыңлый, шул исәптән район Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында да.

## 31 маддә. Район Советының эш тәртибе

1. Район Советының эш тәртибе әлеге Устав һәм район Советының регламенты белән билгеләнә.

2. Район Советы эшенең төп формасы булып аның район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр хәл итә торган утырышлары тора.

3. Район Советы утырышы тулы хокуклы, әгәр анда район Советының сайланган депутатлары санының кимендә 50 проценты катнашса.

4. Район Советының чираттагы утырышлары кирәк саен үткәрелә, әмма өч айга бер тапкырдан да сирәк түгел. Чираттан тыш утырышлар район Башлыгы яки депутатлар төркеме тарафыннан район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бер өлеше инициативасы белән чакырыла.

5. Район Советы утырышлары район Башлыгы тарафыннан чакырыла. Район Советы депутатларына һәм чакырылган кунакларга чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә, ә чираттан тыш утырышныкы – аны үткәрүгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча.

6. Район Советының һәр утырышында утырыш беркетмәсе алып барыла. Утырыш беркетмәсенә утырышны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы мәгълүматлар кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр санап үтелә һәм, тавыш бирү йомгакларын күрсәтеп, кабул ителгән барлык карарлар теркәлә. Район Башлыгы район Советы утырышы беркетмәсенә имза салганнан соң, аның белән районның теләсә кайсы кешесе таныша ала.

7. Район Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Район Советы депутаты тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра. Район Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп) һәм яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Устав, район Советы Регламенты белән билгеләнә..

## 32 маддә. Район Советы эшчәнлеген оештыру

1. Район Советы эшчәнлеген район Башлыгы оештыра.

2. Район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен район Советы регламенты нигезендә депутатлар арасыннан, район

Башлыгыннан һәм аның урынбасарыннан тыш, район Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими комиссияләр төзелә, шулай ук вакытлы комиссияләр төзелергә мөмкин.

3. Муниципаль программаларны, район Советы карарлары проектларын әзерләү, район карамагындагы мөһим мәсьәләләр турында фикер алышу өчен, район Советы каршында аның карары буенча депутатлар, район Башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр вәкилләре, белгечләр, экспертлар һәм район халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшү төркемнәре төзелергә мөмкин.

4. Район Советы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка төрле тәэмин итүне район Советы аппараты гамәлгә ашыра.

## 33 маддә. Район Советының контроль функцияләрен гамәлгә ашыру

1. Район Советы район территориясендә әлеге Устав нигезләмәләренең һәм район Советы тарафыннан кабул ителә торган норматив актларның үтәлешен, район бюджетының үтәлеше, бюджеттан тыш фондлар акчаларын куллану, район үсеше программаларын, район Башкарма комитеты һәм аның җитәкчесе эшчәнлеген контрольдә тота.

2. Районның җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны бозу фактлары ачыкланган очракта район Советы, район Башлыгы карары белән депутатлар арасыннан әлеге фактларны тикшерү өчен вакытлы контроль комиссияләр төзелергә мөмкин.

3. Закон нигезендә район Советы, район Башлыгы карары белән район бюджеты акчаларын максатчан файдалану, муниципаль мөлкәтне куллану нәтиҗәлелегенә тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелергә мөмкин, шулай ук район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча да. Тикшерүләр (ревизияләр) үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә бәйсез аудиторлар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре җәлеп ителергә мөмкин.

4. Район Башкарма комитеты, аның җитәкчесе, предприятие, учреждение, оешмалар, вазыйфаи затлар, әгәр законда башкасы билгеләнмәгән булса, район Советы, аның контроль комиссияләре, район Советы депутаты мөрәҗәгате нигезендә район Советы карамагындагы мәсьәләләр буенча соратыла торган мәгълүматны бирергә, ә кануннарны, муниципаль норматив хокукый актларны бозган очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә тиешләр.

5. Район Советы, контроль функцияләрен башкарганда, район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкарма-күрсәтмә эшчәнлегенә тыкшынырга хаклы түгел.

## 34 маддә. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда

туктатылырга мөмкин:

1) әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә район Советы тарафыннан үзен-үзе тарату турында карар кабул итү;

2) район Советы депутатларының әлеге составының тулы хокуксызлыгы турында Татарстан Республикасы Югары суды карары үз көченә кергәндә, шул исәптән, депутатларның үз вәкаләтләрен туктатуга бәйле рәвештә;

3) "Җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсендәге 4, 6 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган районны үзгәртеп кору, шулай ук район бетерелгән очракта;

4) район чикләрен үзгәртү нәтиҗәсендә сайлаучыларның саны 25 проценттан күбрәккә артып киткәндә;

5) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу.

2. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Район Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлекләрнең вәкиллекле органнары бер ай эчендә район Советы составына башка депутатларны сайларга тиеш.

**35 маддә. Район Советының үзен-үзе тарату турында карар кабул итү тәртибе**

1. Район Советының үзен-үзе тарату турындагы карары район Башлыгы яки район Советы депутатларының яртысыннан да ким булмаган саныннан депутатлар төркеме инициативасы белән кабул ителергә мөмкин.

2. үзен-үзе тарату турында карар кабул итү инициативасы күрсәтелә алмый:

1) район Советы сайланганнан соң беренче ел дәвамында;

2) район бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау чорында;

3) район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылып яңа район Башлыгы сайланганчы.

3. Район Советының үзен-үзе тарату турындагы язма тәкъдимендә үзен-үзе таратуның сәбәпләре булырга тиеш, шулай ук аңа үзен-үзе тарату сәбәпләрен нигезли торган башка материаллар да теркәлергә мөмкин.

4. Район Советы карары белән депутатлар арасыннан үзтаралу мәсьәләсен алдан карау өчен комиссия төзелә. Район Советы яки район Башлыгы карары белән район Советының үзен-үзе тарату турындагы мәсьәлә гавами тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Район Советының үзен-үзе тарату турындагы мәсьәләне карау дәвамлылыгы район Советы депутатлары һәм район халкы тарафыннан үзен-үзе тарату инициативасы буенча төрлеяклап һәм объектив фикер алышу мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үзен-үзе тарату турында карар үзен-үзе тарату турындагы инициативаны тәкъдим иткән көннән ике ай узгач кабул ителергә мөмкин.

6. Район Советының үзен-үзе тарату турындагы карар район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан өчтән икесенең яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

7. Район Советы үзен-үзе тарату турында тәкъдим кире кагылган очракта, үзен-үзе тарату турындагы кабат инициатива, үзен-үзе тарату турындагы мәсьәлә буенча тавыш биргән көннән соң бер ел узгач кына күрсәтелергә мөмкин.

## 36 маддә. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатыла шул очракта:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставка;

3) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә үлгән дип игълан ителсә;

5) аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керүе;

6) Россия Федерациясеннән чыгып китеп башка даими яшәү урынына күчү;

7) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы буларак Россия гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, ә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, чит дәүләт гражданлыгы (подданные) яки яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;

8) район составына керүче тиешле вәкиллекле орган депутаты буларак сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

9) җирлек башлыгы яисә җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак, район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аның үзенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелү;

11) федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.

2. Район Советы депутаты вәкаләтләре “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

3. Район Советының район депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, әгәр бу нигез район Советы утырышлары арасында барлыкка килсә, - шундый нигез барлыкка килгән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Президенты район Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында белдерү (гариза) белән мөрәҗәгать иткән

очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн - әлеге гариза район Советына кергән көн.

4. Тиешле җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, күрсәтелгән орган бер ай эчендә район Советы составына башка депутатны сайларга тиеш.

## Глава IV. РАЙОН БАШЛЫГЫ

### 37 маддә. Район башлыгы – районның иң югары вазыйфаи заты

1. Район Башлыгы районның иң югары вазыйфаи заты (урындагы кешесе) булып тора.

2. Район Башлыгы район Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара.

3. Район Башлыгы вазыйфасының рәсми аталышы – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башлыгы. Район Башлыгы вазыйфасының кыскартылган аталышы – Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы.

### 38 маддә. Район Башлыгын сайлау тәртибе

1. Район Башлыгы район Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән яңа сайланган район Советының беренче утырышында сайлана, әгәр район Советы район Советының вәкаләтләре чорына тавыш бирүнең башка тәртибен, вакытын билгеләми икән.

Район Башлыгын сайлау район Советы депутатлары тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан башкарыла, шул исәптән район халкының, иҗтимагый берләшмәләрнең, Татарстан Республикасы Президентының тәкъдимнәре нигезендә.

2. Район Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен район Советы депутатларының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, район Башлыгы итеп сайланган дип санала.

3. Сайланганнан соң район Башлыгы түбәндәге антны бирә:

“Муниципаль берәмлек Башлыгы вазыйфасына керешкәндә, ант итәм – миңа муниципаль берәмлек Уставы белән бирелгән үз вәкаләтләремне башкарганда, хәзерге һәм киләчәк буыннар алдында муниципаль берәмлек өчен җаваплылыкны аңлап, Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, муниципаль берәмлек Уставын төгәл үтәргә, муниципаль берәмлек халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен ихтирам итәргә, сакларга һәм якларга, тарихи традицияләрне хөрмәт итеп, гражданнар ризалыгына һәм икътисадый потенциалны арттыруга омтылырга, муниципаль берәмлекнең чәчәк атуы һәм аның барлык кешеләренең иминлеге хакына үз вазыйфаларымны намус белән, тугрылыклы башкарырга”.

### 39 маддә. Район Башлыгы статусы

1. Район Башлыгы үз вәкаләтләрен даими нигездә район Советы исеменнән яше буенча иң өлкән район Советы депутаты тарафыннан имзаланган хезмәт шартнамәсе шартларында башкара.

2. Район Башлыгы үз эшчәнлегендә район халкына һәм район Советына федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә контрольдә һәм хисап тота.

3. Район Башлыгы үз эшчәнлеге хакында район Советы алдында елына бер тапкыр хисап тота.

4. Район Башлыгы хаклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерциягә нигезләнмәгән оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан гайре:

а) сәяси фирка, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында яки корылтаенда (конференциясендә) катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итү белән коммерциягә нигезләнмәгән оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси фирка, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында яки корылтаенда (конференциясендә) катнашудан тыш);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) укыту, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.”;

5. Район Башлыгы 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны (вазыйфаларны) башкарырга тиеш.

6. Район Башлыгы 2015 елның 13 июлендәге “Дәүләт-хосусый партнерлык, Россия Федерациясендә муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль-шәхси партнерлык өлкәсендә гавами партнер буларак район исеменнән чыгыш ясый.

### 40 маддә. Район Башлыгының вәкаләтләре

1. Район Башлыгы:

1) районны башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән багланышларда тәкъдим итә, ышанычнамәсез район исеменнән эш итә;

2) район Советы эшен оештыра, район Советы утырышларын җыя һәм аларда рәислек итә;

3) әлеге Устав билгеләгән тәртиптә район Советы кабул иткән норматив хокукый актларга кул куя һәм халыкка җиткерә;

4) үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгара;

5) район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

6) район Советы эшендә җәмәгатьчелек фикеренә хәбәрдарлыкны һәм исәпкә алуны тәэмин итү чараларын күрә;

7) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) район Советының утырышлар беркетмәләренә кул куя;

9) район Советы аппараты эше белән җитәкчелек итә;

10) район Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны яраштыра;

11) район Советы эшчәнлеген тәэмин итүгә район бюджетында каралган чыгымнар буенча эш итүче булып тора;

12) закон һәм әлеге Устав нигезендә гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча район Советының хокукый актын кабул итүне оештыра;

13) район җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән район территориясендә гамәлдә булган хезмәттәшлеген тәэмин итә;

14) район исеменнән икътисадый һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек турында дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек итү һәм гамәлләрне координацияләү турында шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

15) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

16) муниципаль-хосусый партнерлык проектын тормышка ашыру турында карар кабул итә;

17) 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсендәге 2 өлеше нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы районның җирле үзидарә органын билгели;

18) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль районнар башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Устав, район Советы карарлары белән район Башлыгы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 41 маддә. Район Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу очраклары:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 74.1 маддәсе нигезендә отставкага җибәрелү;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 74 маддәсе нигезендә вазыйфадан читләштерелү;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә үлгән дип игълан ителү;

7) аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керү;

8) Россия Федерациясеннән чыгып даими яшәү урынына күчү;

9) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы буларак Россия гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, ә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, чит дәүләт гражданлыгы (подданные) яки яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе

гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;

10) район составына керүче тиешле вәкиллекле орган депутаты буларак сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

11) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 13 маддәсендәге 4, 6 өлешләре нигезендә районны үзгәртеп кору, шулай ук район бетерелгән очракта;

12) район чикләре үзгәрүгә бәйле рәвештә район сайлаучыларының санының 25 проценттан күбрәккә артуы;

13) сәламәтлеге торышы буенча суд тәртибендә район Башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсез дип билгеләнү;

14) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогы бозылу;

15) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү.

2. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки суд карары буенча процессуаль мәҗбүри итү чараларын кулланып сак астына алу яки вазыйфадан вакытлыча азат итү рәвешендәге очракларда аның вәкаләтләрен вакытлыча район Башлыгы урынбасары башкара.

3. Район Башлыгы, аның хатыны һәм балигъ булмаган балалары тарафыннан 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюлар үтәлмәгән очракта, Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалтуга бәйле рәвештә район Башлыгы вәкаләтләре шулай ук вакытыннан алда туктатыла.

4. Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, район Советы тарафыннан үз составыннан сайланучы район Башлыгын сайлау вәкаләтләре шул рәвешле туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Район Советы вәкаләтләре срогы чыкканчы алты айдан кимрәк вакыт калса, район Башлыгын район Советы составыннан сайлау район Советының беренче утырышында башкарыла.

5. Район Башлыгы вазыйфасыннан читләштерү турында Татарстан Республикасы Президентының хокукый акты нигезендә яисә район Башлыгын отставкага җибәрү турында район Советы карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган район Башлыгы әлеге хокукый актка яисә карарга суд тәртибендә шикаять бирә, район Советы, суд карары закон көченә кергәнче, район Советы тарафыннан үз составыннан сайланучы район Башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.

## 42 маддә. Район Башлыгы урынбасары

1. Район Башлыгы тәкъдиме белән депутатлар арасыннан район Башлыгы урынбасары сайлана.

Район Башлыгы урынбасары яшерен яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайлана. Тавыш бирү ысулын сайлау турындагы карар район Советы карары белән тәгаенләнә.

2. Әгәр район Советы депутатын район Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге сайласа, район Башлыгының сайланган урынбасары булып санала.

3. Район Башлыгы урынбасары вазыйфаларын район Советы регламентында билгеләнгән вазыйфаларны бүлү нигезендә башкара, район Башлыгы йөкләмәләрен үти, вакытлыча ул булмаган (авыру яки отпуск белән бәйле) яисә үз бурычларын үтәмәгән очракта яки вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта район Башлыгы вазыйфаларын башкара.

4. Район Башлыгы район Советына үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы бер урынбасарны сайларга тәкъдим итәргә хокуклы.

Район Башлыгы урынбасарының вәкаләтләр вакыты ике елдан ким һәм биш елдан артык була алмый.

5. Район Башлыгы урынбасары вәкаләтләре әлеге Уставның 36 маддәсендә каралган нигезләрдә вакытыннан алда туктатыла.

6. Район Башлыгы урынбасары статусына бәйле башка чикләүләр федераль кануннарда билгеләнгән.

7. Район Башлыгы урынбасары теләсә кайсы вакытта район Советы карары белән вазыйфасыннан алынырга мөмкин, ул район Башлыгы инициативасы буенча яисә район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере күләмендәге депутатлар төркеме таләбе буенча кабул ителә. Район Башлыгы урынбасарын чакыртып алу турындагы карар район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

8. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы район Башлыгы урынбасары хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерцияле яки коммерциягә нигезләнмәгән оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә

җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, коммерциягә нигезләнмәгән хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш алып баручы аларның структур бүлекчәләре составына керергә.";

9. Район Башлыгы урынбасары “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны (йөкләмә-вазыйфаларны) башкарырга тиеш. Район Башлыгы урынбасарының вәкаләтләре вакытыннан алда чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәгән очракта туктатыла, ә алар 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законнарда тәгаенләнгән.

**43 маддә. Ышанычны югалтуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән җибәрү (вазыйфасыннан азат итү)**

1. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат федераль конституциячел законнарда, федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә түбәндәге очракларда ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән җибәрелергә (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш:

1) мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын, низагын) булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча каршылыклар ягында үзе булган зат тарафыннан чаралар күрелмәү;

2) зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырмау яки алдан ук дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат бирү;

3) затның коммерция оешмасы белән идарә итү органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашуы, федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш;

4) зат тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

5) зат Россия Федерациясе территориясендә эш итүче идарә органнары, попечительлек яки күзәтчелек советлары, чит ил коммерциягә нигезләнмәгән хөкүмәтнеке булмаган башка оешмалар һәм аларның структур бүлекчәләре составына керә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына (каршылыгына, низагына) китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль вазыйфаны биләүче зат ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән җибәрелергә (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары күрелмәгән очракта, ә мәнфәгатьләр конфликтында бер як – үзенә буйсынган зат.

3. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата коррупцион хокук бозу кылган өчен ышаныч югалу сәбәпле эштән җибәрү (вазыйфадан азат итү) рәвешендәге җәза бирү турында мәгълүматлар җирле үзидарә органы тарафыннан ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертеләләр, ул “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендә каралган.

4. Җирле үзидарәнең үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат биргән сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр бу мәгълүматларны бозу алай ук мөһим дәрәҗәдә булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итеп, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфадан азат итү;

3) вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан вәкаләтләре вакыты беткәнче мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

5. Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына әлеге маддәнең 4 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

## V бүлек. РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### 44 маддә. Район Башкарма комитеты - район җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы

1. Районның Башкарма комитеты район җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә (боерык бирү) органы булып тора.

2. Район Башкарма комитетының рәсми аталышы (исеме) – "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты", кыскартылган аталышы – Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты.

3. Район Башкарма комитеты район Советы, район Башлыгы һәм район халкы алдында контрольдә һәм хисап тота тота.

4. Район Башкарма комитетының үзенең аталышы (исеме) язылган мөһере, район гербы сурәте төшерелгән бланклары, шулай ук Башкарма комитетка тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе гербы сурәтләнгән түгәрәк мөһере бар.

5. Район Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

### 45 маддә. Район Башкарма комитеты структурасы

1. Башкарма комитет структурасы Башкарма комитет җитәкчесе тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан раслана.

2. Район Башкарма комитеты структурасына Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары керә.

### 46 маддә. Район Башкарма комитетының вәкаләтләре

1. Район Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- район бюджеты проектын төзүне тәэмин итә (бюджет һәм урта сроклы финанс планы проекты);

- кирәкле документлар һәм материаллар белән район бюджеты проектын

(бюджет проекты һәм уртача сроклы финанс планы) район Советы раславына кертә;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бюджетара трансфертларны бүлү методикасын һәм (яисә) бирү тәртибен эшли һәм раслый;

- район бюджетының үтәлешен тәэмин итә һәм бюджет хисабын төзи, район Советы раславына район бюджетының үтәлеше турында хисап тапшыра;

- муниципаль әҗәт белән идарә итүне тәэмин итә;

- районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проектын эшләүне тәэмин итә;

- район бюджетын үтәүне оештыра, районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен тормышка ашыра;

- районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә;

- районның икътисады һәм социаль өлкәсе торышын чагылдыра торган статистик күрсәткечләрне җыюны, күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыруны оештыра;

- җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәләрен район бюджеты акчалары хисабына тигезләүне тәэмин итә.;

- муниципаль кыйммәтле кәгазьләр чыгару, кредитлар алу, муниципаль гарантияләр бирү юлы белән район Советы карарлары нигезендә муниципаль алу-файлалануларны гамәлгә ашыра, муниципаль милеккә нигез сала;

- җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын эшләүне һәм тормышка ашыруны гамәлгә ашыра;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыру мониторингын гамәлгә ашыра;

- стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

2) муниципаль милек белән идарә итү, район территориясендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган эшләргә тарифларны билгели, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итүне һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашыра;

- муниципаль милектәге предприятиеләр, оешмалар белән районның икътисадый һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзи; район территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр төзүгә булышлык күрсәтә;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәрен һәм шартларын билгели;

3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә:

- районны территориаль планлаштыру документларын, районның башка шәһәр төзелеше документлары проектларын эшли һәм аны раслауга кертә һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системаларын алып баруны, муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен алуны, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына туры килүе һәм аларны әлеге җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкинлеге турында һәм параметрларның туры килмәве һәм урнаштыруның мөмкин булмавы хакында хәбәрнамә җибәрүне, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектның тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллауны гамәлгә ашыра, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген алу турында карар кабул итә, авылара территориядә урнашкан үз белдегең белән торгызылган корылманы сүтүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә;

- җирлекара характердагы әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыра;

- район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерып туплауны), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша;

- район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыра, үстерүне һәм саклауны тәэмин итә, җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

- муниципаль урман контролен гамәлгә ашыра;

- "Кадастр эшчәнлеге турында" 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны һәм территориянең карта-планын раслауны оештыра;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итә, район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын контрольдә тота, юл хәрәкәтен оештыру, аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм

юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыра һәм җирлек чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруны тәэмин итә;

- район чикләрендәге торак пунктлар арасында халыкка хезмәт күрсәтүче җәмәгать транспортының маршрутларын, хәрәкәт графигын, тукталыш урыннарын раслый яки килештерә;

- район чикләрендәге торак пунктлардан читтә җәмәгать транспорты тукталышлары өчен бүлеп бирелгән урыннарны төзекләндерүне тәэмин итә;

- район составына керүче авыл җирлекләрен элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- адресация объектларына адреслар бирүне, адресларны үзгәртүне, гамәлдән чыгаруны, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирүне (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларыннан тыш), мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыруны гамәлгә ашыра;

5) торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә, шулай ук төзекләндерү һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә:

- энергияне сак тоту һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслый һәм гамәлгә ашыра, район чикләрендә муниципаль торак фондны тәшкил иткән күпфатирлы йортларга, бүлмәләргә энергетика тикшерүен үткәрүне оештыра, энергияне саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда каралган башка чараларны оештыра һәм үткәрә;

- район чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итүне оештыра;

- район составына керүче авыл җирлекләрен җәмәгать тукланyы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- җирлекара китапханәләрнең халыкка китапханә хезмәте күрсәтүен, китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыра;

- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра һәм район территориясендә җирлекара мәет кую урыннарын карап тотуны тәэмин итә;

- район составына керүче җирлекләрдә җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыра;

- район составына керүче җирлекләрне ял вакытын оештыру һәм мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны булдыра;

- район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калуны, алардан файдалануны һәм аларны популярлаштыруны, район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклауны тәэмин итә;

- җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыра, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итә, социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ирекле-ихтыярилыкка

(волонтерлыкка) ярдәм күрсәтә;

- район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм гаммәви спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыра;

- "Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законда каралган җылылык белән тәэмин итүне оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- "Су белән тәэмин итү һәм субүлү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законда каралган су белән тәэмин итү һәм субүлү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- реклама конструкцияләрен урнаштыру схемаларын раслый, район территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтнамә бирә, мондый рөхсәтнамәләрне юкка чыгара, район территориясендә "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен сүтү турында күрсәтмә бирә;

6) мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә:

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыра (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән гайре), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыра (балаларга өстәмә белем бирүдән тыш, аны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра шулай ук каникул чорында балаларның ялын, аларның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, оештыру чараларын үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра;

- муниципаль мәгариф оешмалары биналарын һәм корылмаларын тотуны, аларга якын территорияләрне төзекләндерүне тәэмин итә;

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә ала, муниципаль мәгариф оешмаларын районның конкрет территорияләренә беркетә;

- муниципаль белем бирү оешмаларын булдыра, үзгәртеп кора, бетерә (муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан югары белем бирүче муниципаль белем бирү оешмаларын булдырудан тыш), муниципаль белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыра (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән җирлекләр территорияләреннән тыш, аларның халкы башкарма хакимиятнең аерым территорияләр халкын медицина-санитария

белән тәэмин итү функцияләрен башкаручы федераль органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә);

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра;

- муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыра, муниципаль хезмәт өчен кадрларны Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә әзерләүне оештыра";

7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

- район территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яисә арбитраж судындаа, җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хокукларын боза торган актларына шикаять бирә;

- муниципаль милиция тарафыннан район территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны оештыруны тәэмин итә;

- район территориясендә гадәттән тыш хәлләр турында кисәтүдә һәм нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша;

- территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм район территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә; гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның җирле резервларын булдыруны тәэмин итә;

- район территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра;

- үз вәкаләтләре чикләрендә һәм билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы яисә барлыкка килү турында халыкка вакытында хәбәр итүне һәм халыкка мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

- су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

- үз вәкаләтләре чикләрендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук район территориясендә терроризм һәм экстремизм чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару буенча чаралар күрүне тәэмин итә;

- район чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын күрә;

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, аз санлы төп халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыру, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итү, милләтара

(этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра;

- районның хезмәт күрсәтелә торган административ участогында полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә эш өчен бина бирүне тәэмин итә;

- 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларны үтәү чорында торак урыны бирүне тәэмин итә;

8) җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс чараларын исәпкә алып бара һәм тиешенчә файдалануны тәэмин итә;

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирә;

- район Советы карарлары нигезендә аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә;

- Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле рәвештә үтүен тәэмин итүне дә кертеп, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгели;

9) башка вәкаләтләр:

- муниципаль хезмәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгели;

- җирлекләрнең архив фондларын саклауны да кертеп, муниципаль архивны формалаштыра һәм тота;

- федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра;

- районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра, законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары белән район Советы, район Башлыгы яки башка җирле үзидарә органнары вәкаләтләреннән тыш.

2. Башкарма комитет районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль район музейларын төзи;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнаша;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

4) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм муниципаль район территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны гамәлгә

ашыруга ярдәм итә;

5) 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагындагы югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен башкара;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтә һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм итә;

8) "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 декабрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре оешмалары тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтә;

9) "Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында" 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыра;

10) авылара территориядәге торак пунктында нотариус булмаган очракта, кануннарда каралган тәртиптә нотариаль гамәлләр башкара;

11) оешмаларга федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыра, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмаларга хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча федераль законнар нигезендә чаралар кабул ителүне тикшереп тору;

12) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра;

13) инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итә;

14) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра;

15) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына әлеге вазыйфаны хезмәткәр биләгән вакытка торак урыны бирә;

16) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра;

17) муниципаль янгын сагын булдыра.

3. Башкарма комитет районның авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә авыл җирлекләре чикләрендә халыкны электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне оештыра;

2) парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле

әһәмияттәге юлларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, юл хәрәкәтен оештыра, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

3) авыл җирлекләрендә яшәүчеләрне һәм аз керемле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗларны торак урыннары белән тәэмин итә, муниципаль торак фондын төзүне һәм тотуны оештыра, торак төзелеше өчен шартлар тудыра, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыра, шулай ук торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

4) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыра;

5) терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук авыл җирлекләре чикләрендә террорчылык һәм экстремизм чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнаша;

6) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнаша;

7) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне, авыл җирлекләре китапханәләренең китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыра;

8) авыл җирлекләре милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калуны, алардан файдалануны һәм аларны популярлаштыруны, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклауны тәэмин итә;

9) җирле халыкның сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыра, авыл җирлекләрендә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнаша;

10) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, махсус сакланылучы табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыра;

11) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә авыл җирлекләренең генераль планнары һәм авыл җирлекләренең башка шәһәр төзелеше документлары проектларын эшли һәм район Советына раслауга кертә, аларның үтәлешен тәэмин итә;

12) авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш) реконструкцияләгәндә, җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлаганда объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә бирә;

13) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карауны гамәлгә ашыруны һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирүне тәэмин итә;

14) район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системаларын алып баруны, муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен алуны,

индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына туры килүе һәм аларны әлеге җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкинлеге турында һәм параметрларның туры килмәве һәм урнаштыруның мөмкин булмавы хакында хәбәрнамә җибәрүне, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектның тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкциялгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллауны гамәлгә ашыра, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген алу турында карар кабул итә, авылара территориядә урнашкан үз белдегең белән торгызылган корылманы сүтүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә;

15) муниципаль ихтыяҗлар өчен авыл җирлекләре чикләрендә җир кишәрлекләрен алуны гамәлгә ашыра;

16) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм авыл җирлекләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыра һәм тормышка ашыруны тәэмин итә;

17) авыл җирлекләре территориясендә авария-коткару хезмәтләре һәм (яки) авария-коткару формированиеләре эшчәнлеген булдыра, тәэмин итә;

18) авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларны тормышка ашыруны оештыра;

19) авыл җирлекләре территорияләрендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыра, үстерүне һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигый территорияләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

20) Россия Федерациясенең су законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, халыкка аларны куллану чикләүләре турында хәбәр итә;

21) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыра;

22) авыл җирлекләренең хезмәт күрсәтелә торган административ участокларында полиция участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә эш өчен бина бирүне тәэмин итә;

23) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полициянең участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфа буенча вазыйфаларны үтәү чорында торак урыннары бирүне тәэмин итә;

24) “Коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар турында” 12.01.1996 ел, № 7-ФЗ Федераль законның 31.1 һәм 31.3 маддәләрендә билгеләнгән вәкаләтләр

кысаларында социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтә;

25) авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыра;

26) 2007 елның 24 июлендәге "Кадастр эшчәнлеге турында" 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнаша;

27) җылылык белән тәэмин итү системасының үсеше, ышанычлылыгын һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле һәм аның өчен җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән "Җылылык белән тәэмин итү турында" 27.07.2010 ел, № 190-ФЗ Федераль закон белән тәгаенләнгән вәкаләтләр чикләрендә билгеләнгән җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча чараларның үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра.

4. Район башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль өлкәсендә район Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны оештыру һәм үткәрү, аны үткәрү күрсәткечләре һәм методикасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана, авыл җирлекләрендә вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрольдән тыш;

5) федераль законнарда, законнарда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре район Башкарма комитеты органнарына мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль берәмлек чикләрендә тиешле контроль объектлары булганда муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

5. Район башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә, терроризмны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча:

1) терроризмны профилактикалау, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү өлкәсендә муниципаль программаларны эшли һәм тормышка ашыра;

2) районда терроризмның асылын һәм аның иҗтимагый хәтәрлеген аңлату буенча мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү буенча, шул исәптән мәгълүмат материалларын, матбугат продукциясен тарату, аңлату эшләре алып бару һәм башка чаралар уздыру юлы белән;

3) террорчылыкны профилактикалау чараларында катнаша, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча;

4) муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

5) террорчылыкны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча, шулай ук аның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрә;

6) террорчылыкны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**47 маддә. Район Башкарма комитеты җитәкчесе**

1. Район башкарма комитетын Башкарма комитет җитәкчесе җитәкли.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге вазыйфага контракт буенча билгеләнүче җирле үзидарәнең вазыйфаи заты (урындагы кешесе) булып тора.

3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе үз вәкаләтләрен даими нигездә башкара.

4. Аерым оештыру-боеру функцияләрен гамәлгә ашыру өчен район Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарлары бар. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вакытлыча булмаганда (авыру яки отпускка бәйле рәвештә) яки үз бурычларын үти алмаган очракта яисә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда аның вазыйфаларын урынбасарларының берсе билгеләнгән вазыйфалар бүленешенә туры китереп башкара.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

6. Район Башкарма комитеты җитәкчесе 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга тиеш.

## 48 маддә. Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү тәртибе

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә үткәрелә.

Конкурс шартлары, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүматлар, контракт проекты гаммәви мәгълүмат чараларында конкурс уздырылу көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (игълан ителергә) тиеш.

2. Конкурсны үткәрү өчен конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны район Советы тарафыннан билгеләнә.

Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы – район Советы, ә икенче яртысы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан тәгаенләнә.

3. Зат район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан район Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Район Башкарма комитеты җитәкчесе өчен контракт шартлары район Советы тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә раслана һәм Татарстан Республикасы законы белән – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт район Башлыгы тарафыннан төзелә.

## 49 маддә. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре вакыты

1. Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына затны билгеләү турында карар кабул иткән район Советы вәкаләтләре чорына төзелә (яңа чакырылыш район Советы эшли башлаганчы), әмма ике елдан ким һәм биш елдан артык түгел.

2. Район Советы вәкаләтләре вакыты чыккач, район Башкарма комитеты җитәкчесе үз вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә район Башкарма комитетының яңа җитәкчесе билгеләнгәнче дәвам итә.

## 50 маддә. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре

1. Башкарма комитеты җитәкчесе:

1) район Башкарма комитеты эшчәнлеге белән берүзе идарә итү принцибында җитәкчелек итә һәм район Башкарма комитеты тарафыннан аның компетенциясенә кергән вәкаләтләрне үтәү өчен шәхсән җаваплылык тота;

2) район Советы, район Башлыгы, районның башка җирле үзидарә органнары һәм башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән багланышларда район Башкарма комитетын тәкъдим итә;

3) район бюджеты проектларын һәм аның үтәлеше турында хисапларны район Советы каравына тәкъдим итә;

4) район Советы каравына районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын һәм аны тормышка ашыру турында хисап тәкъдим итә;

5) Башкарма комитет структурасы проектын район Советы раславына кертә, район Башкарма комитетының штат расписаниесен хезмәткәрләрнең чик саны һәм хезмәт өчен түләү фонды белән билгеләнгән расланган структура нигезендә раслый;

6) Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфаларны бүлә, район Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләрен һәм башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

7) расланган бюджет нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә район акчалары белән эш итә;

8) район Башкарма комитеты тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә, аларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота; тиешле законнар нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара;

9) үз вәкаләтләре кысаларында хокукый актлар чыгара;

10) район Башлыгы, район Советы таләбе буенча елга бер тапкырдан да ким итмичә район Советына район Башкарма комитеты эшчәнлеге һәм үзенең эшчәнлеге турында хисап бирә;

11) район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими мәгълүмат җиткерә, район Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга кимендә бер тапкыр гражданнарны кабул итүне гамәлгә ашыра, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

12) дәүләт һәм башка органнарда район мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар күрә, район Башкарма комитеты исеменнән судка гариза тапшыра, ышанычнамәләр бирә;

13) район Башкарма комитеты органнары турындагы нигезләмәләрнең проектларын район Советы раславына тәкъдим итә;

14) район Советы билгеләгән тәртиптә район Башкарма комитеты органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә;

15) законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары һәм контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

### 51 маддә. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда шул очракта туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) әлеге маддәнең 2 яисә 3 өлеше нигезендә контрактны өзү;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 74 маддәсе нигезендә вазыйфадан читләштерелү;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә үлгән дип игълан ителү;

7) аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керү;

8) Россия Федерациясеннән чыгып китеп башка даими яшәү урынына күчү;

9) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы буларак Россия гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, ә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, чит дәүләт гражданлыгы (подданные) яки яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә юлламалар;

11) Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 13 маддәсендәге 4, 6 өлешләре нигезендә районны үзгәртеп кору, шулай ук район бетерелгән очракта;

12) район чикләре үзгәрүгә бәйле рәвештә район сайлаучыларының санының 25 проценттан күбрәккә артуы;

13) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогы бозылу;

14) район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен башкаручының район Башлыгы вазыйфасына керешүе.

2. Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт якларның килешүе буенча яки суд тәртибендә гариза нигезендә өзелергә мөмкин:

1) район Советы яки район Башлыгы - контрактның шартлары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлешендә бозылуга бәйле рәвештә, шулай ук законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;

2) Татарстан Республикасы Президенты - районның җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә контракт шартлары бозылуга бәйле рәвештә, шулай ук законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;

3) Башкарма комитет җитәкчесе - районның җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан контракт шартлары бозылуга бәйле рәвештә.

3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ номерлы Федераль

закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законнар белән билгеләнгән коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (белдерүе) нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин.

4. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары башкара.

## VI бүлек. РАЙОН СОВЕТЫ, РАЙОН БАШЛЫГЫ ҺӘМ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ АРАСЫНДАГЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘР

### 52 маддә. Район Советының, район Башлыгының һәм район Башкарма комитетының үзара хезмәттәшлеге нигезләре

1. Әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү нигезендә район Советы, район Башлыгы һәм район Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыралар.

2. Район Советы һәм район Башкарма комитеты районның икътисади һәм социаль үсеше процесслары белән нәтиҗәле идарә итү максатыннан, законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән формаларда һәм аның халкы мәнфәгатьләрендә хезмәттәшлек итәргә тиеш.

3. Район Советы һәм район Башкарма комитеты кабул ителгән хокукый актларны кул куйган көннән җиде көн эчендә бер-берсенә җибәрәләр.

4. Район Советы, район Башлыгы район Башкарма комитеты җитәкчесенә район Башкарма комитетының хокукый актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, Башкарма комитетның башка вазыйфаи затларын да, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе район Советына, район Башлыгына район Советының, район Башлыгының хокукый актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

6. Район Башлыгы район Башкарма комитеты җитәкчесенә район Советының эш планнарын һәм район Советы карарлары проектларын район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

7. Район Советы утырышларында, аның органнары утырышларында, район Башлыгы үткәрә торган утырышларда киңәш бирү тавышы хокукы белән район Башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары яки алар тарафыннан вәкаләтле затлар катнаша ала. Район Башкарма комитетының вазыйфаи затлары, язма рәвештә чакырылган очракта, район Советы утырышларында катнашырга тиеш.

8. Район Башкарма комитеты җитәкчесе үткәрә торган утырышларда район Башлыгы, район Советы депутатлары катнашырга хокуклы.

### 53 маддә. Районның җирле үзидарә органнары арасындагы бәхәсләрне хәл итү

1. Районның җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр килештерү процедураларын уздыру юлы белән яисә суд тәртибендә хәл ителә.

## VII бүлек. РАЙОННЫҢ БАШКА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ

### 54 маддә. Районның Контроль-хисап палатасы

1. Районның контроль-хисап палатасы тышкы муниципаль финанс контроле җирле үзидарәсенең даими эшләүче органы булып тора һәм район Советы тарафыннан төзелә.

Районның контроль-хисап палатасы оештыру һәм функциональ бәйсезлеккә ия һәм үз эшчәнлеген мөстәкыйль алып бара.

2. Районның контроль-хисап палатасы район Советы алдында хисап тота.

3. Районның контроль-хисап палатасы контроль-хисап палатасы рәисе һәм аппараты составында төзелә.

Районның контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасы муниципаль вазыйфа булып тора.

4Районның контроль-хисап палатасы рәисе үз вазыйфасына район Советы тарафыннан билгеләнә. Районның контроль-хисап палатасы рәисенең вәкаләтләр чоры - алты ел.

Район Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр район Советына тъбщндщгелщр тарафыннан кертелә:

- район Башлыгы;

- район Советы депутатлары – район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере.

Район Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү һәм әлеге тәкъдимнәрне карау тәртибе район Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Районның Контроль-хисап палатасы Рәисе вазыйфасын биләүгә бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

Районның Контроль-хисап палатасы рәисе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав белән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

6. Районның контроль-хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) район бюджеты үтәлешен контрольдә тоту;

2) район бюджеты проектларына экспертиза;

3) район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) район бюджеты акчаларын куллануның законлылыгына, нәтиҗәлелегенә (эффектлылыгына һәм экономиялелегенә) контрольлек итүне оештыру һәм тормышка ашыру, шулай ук район бюджеты тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган башка чыганаклардан алына торган акчаларны да исәпкә алу;

5) муниципаль милектә булган мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту, шул исәптән саклана торган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм районныкы булган индивидуальләштерү чаралары белән дә;

6) район бюджеты акчалары хисабына салым һәм башка ташламалар, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук район бюджеты һәм муниципаль милектәге мөлкәт акчалары исәбеннән башкарыла торган юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан муниципаль гарантияләрнең һәм поручительлекләрнең законлылыгына бәя бирү яисә йөкләмәләр үтәлешен башка ысуллар белән тәэмин итү;

7) районның чыгым йөкләмәләренә, шулай ук муниципаль программаларга кагылышлы өлешендә муниципаль хокукый актлар проектларына (финанс-икътисадый нигезләрнең нигезлелеген дә кертеп) финанс-икътисадый экспертиза;

8) районда бюджет процессын анализлау һәм аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләү;

9) район бюджеты үтәлеше, үткәрелгән контроль һәм экспертиза-аналитик чаралар нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм мондый мәгълүматны район Советына һәм район Башлыгына тапшыру;

10) вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларда катнашу;

11) район составына керүче җирлекләр бюджетларына кергән район бюджеты акчаларын куллануның законлылыгына, нәтиҗәлелегенә (эффектлылыгына һәм экономиялелегенә) контроль;

12) район Советы һәм җирлек Советы төзегән килешүләр нигезендә район составына керүче җирлекләрдә тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру;

13) чыгым йөкләмәләре реестрына кертелгән чыгым йөкләмәләре һәм район бюджеты проекты нигезендә чираттагы финанс елында финанслануга планлаштырыла торган чыгым йөкләмәләре арасында туры килү-килмәүне ачыклау буенча районның чыгым йөкләмәләре реестрының мәгълүматлар анализы;

14) муниципаль программаларны гамәлгә ашыру барышын һәм нәтиҗәләрен тикшерү;

15) район бюджеты үтәлеше мониторингы;

16) райондагы социаль-икътисадый хәлгә анализ;

17) җирле үзидарә органнарында эчке финанс контролен оештыруга ярдәм итү;

18) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав һәм

район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендә башка вәкаләтләр.

7. Тикшерү-хисап палатасы тарафыннан башкарыла торган тикшерүләр нәтиҗәләре район Советы утырышында карап фикер алышырга, шулай ук рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

8. Районның контроль-хисап палатасы юридик зат хокукларына ия, аның үзенең аталышы (исеме) һәм район гербы сурәтләнгән герблы мөһере һәм бланклары бар.

## 55 маддә. Районның финанс-бюджет палатасы

1. Районның финанс-бюджет палатасы район җирле үзидарәсенең даими эшләп килүче финанс органы булып тора, ул эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыра. Районның финанс-бюджет палатасы түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

- район бюджеты проектын (бюджет проекты һәм уртача вакытка исәпләнгән финанс планы) төзи;

- район бюджеты проектын (бюджет проекты һәм уртача вакытка исәпләнгән финанс планы) район Советына раслауга кертү өчен кирәкле документлар һәм материаллар белән район Башкарма комитетына тапшыра;

- район бюджеты үтәлешен оештыра;

- җирле үзидарә финанс органының Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) район нигезендә кабул ителә торган, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләре.

2. Җирле үзидарәнең финанс органы вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда районның финанс-бюджет палатасы район Советына хисап тота.

3. Районның финанс-бюджет палатасы үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм район Советы раслаган Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

Районның финанс-бюджет палатасы рәисе район Башлыгы тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан билгеләнә. Районның финанс-бюджет палатасы рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан билгеләнә.

4. Районның финанс-бюджет палатасы рәисе район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булып тора, районның финанс органы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

5. Районның финанс-бюджет палатасының мөһере, район гербы сурәтләнгән һәм үз исеме (аталышы) белән бланклары бар.

6. Районның финанс-бюджет палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## 56 маддә. Районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы

1. Районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы районның даими эшләүче

җирле үзидарә органы булып тора, ул түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- районның муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итә, шул исәптән район милкендә булган җир кишәрлекләре, акцияләр, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларындагы өлешләр (кертемнәр), муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, куллану, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- район Советы карары белән билгеләнә торган очракларда муниципаль мөлкәтне читләштерү турында, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәрне район Советы тарафыннан килештерүгә (раслауга) әзерли;

- муниципаль милектәге җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыра һәм оештыра;

- район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны, "Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 19.07.2011 ел, № 246-ФЗ Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрүне тәэмин итә;

- районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 31.07.2020 ел, № 248-ФЗ Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

- муниципаль мөлкәт реестрын Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән тәртиптә алып бара;

- муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервта саклауны башкара.

Районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда район Советы алдында хисап тота.

2. Районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы районның авыл җирлекләре территорияләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- муниципаль ихтыяҗлар өчен авыл җирлекләре чикләрендә җирләрне резервта саклауны гамәлгә ашыра;

- авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 31.07.2020 ел, № 248-ФЗ Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

- авыл җирлекләре ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны, "Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 19.07.2011 ел, № 246-ФЗ Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрүне тәэмин итә.

3. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

4. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе район Башлыгы тәкъдиме

буенча район Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булып тора, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

6. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының мөһере, район гербы сурәтләнгән һәм үз исеме (аталышы) булган бланклары бар.

7. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## VIII бүлек. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

### 57 маддә. Районның сайлау комиссиясе

1. Район сайлау комиссиясе муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алуны, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча әзерләүне һәм тавыш бирүне оештыра.

2. Районның сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган булып тора.

3. Районның сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Сайлау кодексында, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә район Советы тарафыннан төзелә.

Районның сайлау комиссиясе түбәндәгеләрнең тәкъдимнәре нигезендә төзелә: Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси фиркаләр, шулай ук район Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре; башка сәяси фиркаләр һәм бүтән иҗтимагый берләшмәләр; яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышлары; элекке составтагы район сайлау комиссиясе; Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе.

4. Район Советы район сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан яртысын түбәндәгеләрдән кергән тәкъдимнәр нигезендә билгеләп куярга тиеш:

1) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси фиркаләр;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси фиркаләр;

3) район Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре.

5. Район Советы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кергән тәкъдимнәре нигезендә район сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысын билгеләп куярга тиеш.

6. Район сайлау комиссиясе вәкаләтләре срогы биш ел тәшкил итә.

7. Районның сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия 8 әгъза

составында төзелә.

8. Район сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

9. Район сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән җайга салына. Район Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча район сайлау комиссиясе вәкаләтләре территория сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

## IX бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ГРАЖДАНЛЫК-ХОКУКЫЙ ҺӘМ ФИНАНС НИГЕЗЛӘРЕ

### 58 маддә. Юридик зат хокукларына ия районның җирле үзидарә органнары

1. Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә юридик зат хокуклары район Советы һәм район Башкарма комитетына, районның Финанс-бюджет палатасына, районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына, районның Контроль-хисап палатасына бирелә.

2. Район Советы карары белән юридик зат хокукы башка муниципаль органнарга да, шулай ук район Башкарма комитеты структурасы нигезендә аның аерым органнарына да бирелергә мөмкин.

### 59 маддә. Юридик затлар буларак районның җирле үзидарә органнары

1. Район исеменнән мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычлар алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәсез чыгыш ясарга район Башкарма комитеты җитәкчесе мөмкин.

2. Район башлыгы мөлкәти һәм башка хокукларны һәм бурычларны ала һәм гамәлгә ашыра, район Советы, район Башлыгы, депутатлар эшчәнлеген тәэмин итүгә җибәрелә торган район бюджеты чаралары белән, шулай ук район Советына беркетелгән муниципаль милек белән эш итүгә бәйле рәвештә судта ышанычнамәсез чыгыш ясый.

3. Юридик зат хокуклары булган районның җирле үзидарә органнары идарә функцияләрен гамәлгә ашыру өчен төзелә торган муниципаль казна учреждениеләре булып торалар һәм юридик затлар буларак федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узарга тиеш.

### 60 маддә. Районның җирле үзидарә органнарын финанслау

1.Районның җирле үзидарә органнарын тоту чыгымнары район бюджетының үз керемнәре исәбеннән финанслана.

2. Законда, әлеге Уставта, район Советы карарларында каралган очракларда районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар район

бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## X бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ УЗУ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮ

### 61 маддә. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт – хезмәт шартнамәсе (контракт) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырылучы гражданнарның һөнәри эшчәнлеге.

2. Муниципаль хезмәтне финанслау район бюджеты хисабына башкарыла.

3. Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнар муниципаль хезмәткә тигез мөмкинлеккә һәм җенесенә, расага, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга бәйсез рәвештә аны узуның тигез шартларына ия булалар.

4. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләренә, вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, белем һәм күнекмәләр стажына туры килү таләп ителә, шулай ук яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) тиешле карары булганда – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә.

Һөнәри белем бирү дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен кирәкле белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 ел, № 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 8 маддәсендәге 3 өлешендә билгеләнгән типлаштырылган (бер үк рәвештәге) квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

### 62 маддә. Муниципаль хезмәт вазыйфасы

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – әлеге Устав нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы, районның сайлау комиссиясе аппаратындагы җирле үзидарә органы, район сайлау комиссиясе яисә муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча вазыйфаларның билгеләнгән даирәсендә куелган тәртиптә башкарылуын тәэмин итү буенча вазыйфа.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры

нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе аппаратының штат расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемнәре (аталышлары) кулланыла.

## 63 маддә. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, муниципаль хезмәткәр

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып торалар ("Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсендәге 1 өлешенең унтугызынчы абзацы нигезендә әлеге затларны тәгаенләргә).

2. Муниципаль хезмәткәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфалары буенча район бюджеты акчалары исәбеннән хезмәте өчен акча түләнә торган вазыйфа (бурычлар, йөкләмәләр) башкаручы граждан ул.

3. Җирле үзидарә органнары, районның сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмиләр һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормыйлар.

## 64 маддә. Муниципаль хезмәткәрнең хокуклары һәм бурычлары

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәтне биләгән вазыйфасы буенча аның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче документлар, вазыйфаи бурычларның үтәлеше сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча алга китү (мену) шартлары белән танышу;

2) вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле оештыру-техник шартларны тәэмин итү;

3) хезмәт өчен түләү һәм хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт шартнамәсе (контракт) нигезендә башка түләүләр;

4) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәре һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәре бирү белән тәэмин ителә торган ял, шулай ук еллык түләүле отпуск;

5) вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алу, шулай ук җирле үзидарә органы, Районның сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү;

6) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста үз инициативасы белән катнашу;

7) җирлек бюджеты акчалары исәбеннән муниципаль хокукый акт нигезендә өстәмә һөнәри белем алу;

8) шәхси мәгълүматларны саклау;

9) шәхси эшенең барлык материаллары, һөнәри эшчәнлекләре турында фикерләр һәм аларны шәхси эшенә керткәнче башка документлар белән танышу, шулай ук аның язма аңлатмаларын шәхси эшенә теркәп кую;

10) һөнәри берлекләр төзү хокукын да кертеп, үз хокукларын, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен берләшү;

11) хезмәт законнары нигезендә индивидуаль хезмәт бәхәсләрен карау, муниципаль хезмәттә үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларны бозуларга карата судка шикаять белдерүне дә кертеп;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэмин итү.

2. Муниципаль хезмәткәр, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан язма рәвештә хәбәрнамә юллап башка түләүле эшне башкарырга хокуклы, әгәр дә бу мәнфәгатьләр конфликтына (каршылыгына, низагына) китермәсә һәм әгәр башкасы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралмаган булса.

3. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Устав һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәргә;

3) вазыйфаи бурычларын башкарганда, расасына карамастан, кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, милләтләре, теле, дингә мөнәсәбәтенә карамастан һәм башка шартларны, шулай ук оешмаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәргә;

4) Районның җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе, вазыйфаи инструкция кагыйдәләрен, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларны тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматларны, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган мәгълүматларны фаш итмәскә, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагылышлы мәгълүматларны;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән аңа вазыйфаи бурычларны башкару өчен бирелгән мөлкәтне сакларга;

8) үзе һәм гаиләсе әгъзалары турында Россия Федерациясе законнарында каралган мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын (подданствосын) туктату турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәлергә яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданствосы), аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга

хокуклы;

10) чит ил гражданлыгын (подданствосын) алу яки чит ил гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне язма рәвештә хәбәр итәргә, тик чит ил гражданлыгын (подданствосын) алган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча яки яшәүгә рөхсәт яки гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу турында хәбәр итәргә;

11) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, йөкләмәләрне башкарырга, тыюларны бозмаска;

12) мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган вазифаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә язмача хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау буенча чаралар күрергә;

4. Муниципаль хезмәткәр үзенә бирелгән хокукка каршы килә торган йөкләмәне үтәргә хаклы түгел. Муниципаль хезмәткәр фикеренчә, хокук белән сыешмаучы йөкләмәне (йомышны) тиңдәшле җитәкчедән алганда, муниципаль хезмәткәр, федераль законнар нигезләмәләрен күрсәтеп, әлеге йөкләмәнең хокукка каршы килүен Федераль канун нигезләмәсенә, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларга (алар йөкләмәне, йомышны) үтәгәндә бозылырга мөмкин) таянып язма рәвештә нигезләүне йөкләмә биргән җитәкчегә тапшырырга тиеш. Әлеге йөкләмәнең җитәкчесе тарафыннан язма рәвештә расланган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Законсыз йөкләмәне үтәгән очракта, муниципаль хезмәткәр һәм бу йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## 65 маддә. Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр

1. Муниципаль хезмәткәргә гарантияләнә:

1) вазыйфаи инструкция нигезендә аның вазыйфаи бурычларын үтәвен тәэмин итә торган эш шартлары;

2) акчалата керемне үз вакытында һәм тулы күләмдә алуга хокук;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәрен һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрен бирү, шулай ук еллык түләүле отпускны тәэмин итә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыккач;

5) тиешле еллар эшләгән өчен һәм инвалидлык белән бәйле рәвештә пенсия белән тәэмин итү, шулай ук муниципаль хезмәткәр гаиләсе әгъзаларын вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә вафат булган очракта пенсия белән тәэмин итү;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерү очрагына мәҗбүри дәүләт иминләштерүе;

7) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узганда яисә ул туктатылганнан соң авыру очрагында яисә хезмәткә сәләтне югалткан очракта мәҗбүри дәүләт социаль иминләштерүе, ләкин вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә

килеп чыккан очракта;

8) федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда аның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларына көч кулланудан, янаулардан һәм башка хокук булмаган гамәлләрдән яклау.

2. Җирле үзидарә органы, районның сайлау комиссиясе бетерелүгә яки җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штаты, район сайлау комиссиясе аппараты кыскартылуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә муниципаль хезмәткәргә оешма бетерелүгә яки оешма хезмәткәрләре штаты кыскаруга бәйле рәвештә хезмәткәрләр өчен эштән чыгарылган очракта, хезмәткәрләргә хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.

### 66 маддә. Муниципаль хезмәткәрнең дисциплина җаваплылыгы

1. Дисциплинар гамәл кылган өчен – үзенә йөкләнгән хезмәт бурычларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү өчен – яллаучының (эш бирүче) вәкиле түбәндәге дисциплинар җәзалар кулланырга хокуклы:

1) искәртү;

2) шелтә;

3) муниципаль хезмәттән тиешле нигезләрдә эштән азат итү.

2. Дисциплинар җинаятькә юл куйган муниципаль хезмәткәр, аның дисциплинар җаваплылыгы турындагы мәсьәләне хәл иткәнче, вакытлыча (ләкин бер айдан да артык түгел) булырга мөмкин, акчалата түләүне саклап калып, вазыйфаи бурычларны үтәүдән читләштерелергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне вазыйфаи бурычларын үтәүдән читләштерү бу очракта муниципаль хокукый акт белән башкарыла.

3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш.

## XI бүлек. РАЙОН БАШЛЫГЫНЫҢ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮЧЕ БАШКА ЗАТЛАРНЫҢ СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ГАРАНТИЯЛӘРЕ

### 67 маддә. Район башлыгы һәм аның урынбасары, район Советы депутатлары, районның Контроль-хисап палатасы рәисе, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре

1. Район Башлыгына һәм аның урынбасарына, район Советы депутатларына, районның Контроль-хисап палатасы рәисенә, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, әлеге Устав һәм район Советы карарлары белән билгеләнә.

2. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка гарантияләнә:

1) муниципаль хокукый актлар нигезендә вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итә торган эш шартлары;

2) милек рәвешләренә бәйсез рәвештә җирле үзидарә органнарының, җирле бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган яки салымнар һәм мәҗбүри түләүләр буенча ташламаларга ия, яисә җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә куелган һәм район территориясендә урнашкан органнар буларак законнар нигезендә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта кабул итүгә хокук;

3) районның җирле үзидарә органнары кабул иткән хокукый актларга тоткарлыксыз керү хокукы;

4) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә районның тиешле территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнарыннан, ә федераль законнарда каралган очракларда - барлык милек рәвешләрендәге оешмалардан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм аларның вазыйфаи затларыннан алу хокукы;

5) акчалата хак түләүне үз вакытында һәм тулы күләмдә алуга хокук;

6) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәре һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәре бирү белән тәэмин ителә торган ял, шулай ук еллык түләүле төп һәм өстәмә отпусклар;

7) муниципаль вазыйфаны биләүче затка һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү, шул исәптән муниципаль вазыйфа биләүче зат пенсиягә чыккач та;

8) муниципаль вазыйфа зат тарафыннан биләгән чорда яисә ул туктатылганнан соң авыру очрагына яисә хезмәткә сәләтне югалткан очракта мәҗбүри дәүләт социаль иминләштерүе, вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә килеп чыккан очракта;

9) пенсия белән тәэмин итү “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат гаилә әгъзаларын, аның федераль законнар нигезендә вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан үлеме очрагында пенсия белән тәэмин итү;

10) муниципаль вазыйфаны биләүче затны һәм аның гаилә әгъзаларын түбәндәге очракларда, тәртиптә һәм шартларда аларның вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә көч кулланудан, янаулардан һәм башка хокукый булмаган гамәлләрдән федераль законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә яклау;

11) хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау;

12) үз вәкаләтләрен башкарганда транспорт хезмәте күрсәтү, шулай ук хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен биләгән вазыйфага бәйле

рәвештә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә компенсация.

3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка әлеге маддәнең 2 өлешендәге 1 - 4 һәм 10 пунктларында каралган гарантияләр бирелә, муниципаль вазыйфаны биләүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү гарантияләнә, шул исәптән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфа биләүгә бәйле рәвештә хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны, шулай ук дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек Уставында билгеләнә торган чорга эш (вазыйфа) урынын саклап калу, ул тулаем алганда аена икедән ким һәм алты эш көненнән артык була алмый.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслана.

**68 маддә. Район Башлыгының, район Советы депутатларының кагылгысызлык гарантияләре**

1. Район Советы депутатларының, шул исәптән район Башлыгының, хокуклары гарантияләре аларны җинаять яки административ җаваплылыкка тартканда, тоткарлаганда, кулга алганда, тентүдә, сорау алганда, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук алар биләгән торак һәм (яисә) хезмәт урыны, аларның багажы, шәхси һәм хезмәт транспорт чаралары, аларның кулланыла торган элемтә чаралары, алар карамагындагы документлар булган депутатларга карата оператив-эзләү чаралары үткәрү федераль законнар белән билгеләнә.

2. Федераль закон нигезендә район Советы депутаты, шул исәптән район Башлыгы, әйтелгән фикер, тавыш биргәндә белдерелгән позиция өчен һәм аларның статусына туры килә торган башка гамәлләр, шул исәптән аның вәкаләтләре срогы чыккач та, җинаять яки административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин түгел.

Әлеге нигезләмә район Советы депутаты тарафыннан халык алдында кимсетүләр, яла ягу яисә федераль законда каралган башка хокук бозуларга караган очракларга кагылмый.

## XII бүлек. РАЙОН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

**69 маддә. Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы**

1. Район җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары федераль законнар нигезендә район халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында җаваплы.

**70 маддә. Район Советы депутатларының район халкы алдында җаваплылыгы**

1. Район Советы депутатларының, шул исәптән район Башлыгының, район халкы алдында җаваплылыгы депутатны сайлаган район халкының ышанычын

югалту нәтиҗәсендә барлыкка килә.

2. Ышанычын югалткан район Советы депутаты, шул исәптән район Башлыгы, җирлекнең вәкиллекле органы депутаты буларак федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә чакыртып алынырга мөмкин.

### 71 маддә. Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының дәүләт алдындагы җаваплылыгы

1. Федераль закон нигезендә район Советының, район Башлыгының, район Башкарма комитеты җитәкчесенең дәүләт алдында җаваплылыгы Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Уставны бозган өчен, шулай ук районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырмаган очракта тиешле суд карары нигезендә башлана.

### 72 маддә. Физик һәм юридик затлар алдында район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы

1. Физик һәм юридик затлар алдында район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә башлана.

## XIII бүлек. РАЙОННЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

### 73 маддә. Районның муниципаль хокукый актлары системасы

1. Районның муниципаль хокукый актлары системасына керә:

1) район Уставы;

2) җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар;

3) район Советының норматив һәм башка хокукый актлары;

4) район Башлыгының, Башкарма комитетның, башка органнарның һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының әлеге Уставта каралган хокукый актлары.

2. Район Уставы һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар муниципаль хокукый актлар системасында югары юридик көчкә ия актлар булып торалар, турыдан-туры гамәлдә һәм районның бөтен территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актларга каршы килмәскә тиеш.

3. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар районның бөтен территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш.

Муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен гражданнар, оешмалар җитәкчеләре, дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затлары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары федераль законнар һәм Татарстан Республикасы

законнары нигезендә җаваплы.

4. Муниципаль хокукый актлар Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килмәскә тиеш.

Муниципаль хокукый актлар юкка чыгарылырга яисә аларның гамәлдә булуы тиндәшле муниципаль хокукый актны кабул иткән (бастырган) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан мондый органнар яисә тиешле вазыйфалар юкка чыгарылган яисә күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затларның вәкаләтләре исемлеге үзгәртелгән очракта туктатылырга мөмкин - җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, алар вәкаләтләренә муниципаль хокукый актны кабул итү (бастырып чыгару) кертелгән, шулай ук суд тарафыннан; ә җирле үзидарә органнарының федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала торган өлешендә - Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы).

Норматив характерга ия булмаган муниципаль хокукый актның гамәлдә булуы кичекмәстән районның җирле үзидарә органы яисә районның җирле үзидарә вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителгән (чыгарган) очракта аның тарафыннан Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилнең Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән тиешле күрсәтмәсен алу белән туктатыла. Бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше турында район Башкарма комитеты яисә районның җирле үзидарә вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә өч көн эчендә хәбәр итәргә тиеш, ә район Советы - карар кабул ителгән көннән соң өч көннән дә соңга калмыйча.

5. Муниципаль норматив хокукый актларда эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү тәртибе һәм аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль кысаларында, административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтнамәләр бирү, аккредитацияләү, бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләрендә башкарыла (алга таба - мәҗбүри таләпләр), алар “Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында” 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү принципларын исәпкә алып, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

6. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны урынсыз кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган экспертиза булырга мөмкин.

## 74 маддә. Гражданнарның турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры район гражданнары тарафыннан хәл итү җирле референдумда белдерелгән гражданнарны турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр район халкының турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль норматив хокукый акт кабул итү таләп ителсә, күрсәтелгән актны кабул итү вәкаләтләренә керә торган җирле үзидарә органы яисә районның җирле үзидарә органы вазыйфаи заты, референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 15 көн эчендә тиешле муниципаль норматив хокукый актны әзерләү һәм кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

3. Гражданнарның турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу район Башлыгын чакыртып алу, район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки Совет вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.

## 75 маддә. Район җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар төрләре

1. Район җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән түбәндәге муниципаль хокукый актларны чыгаралар:

1) район Советы – район Советы карарлары;

2) район Башлыгы - район Башлыгы карарлары һәм боерыклары (күрсәтмәләре);

3) район Башкарма комитеты җитәкчесе - район Башкарма комитеты карарлары һәм боерыклары.

2. Район җирле үзидарәсенең башка вазыйфаи затлары әлеге Устав, аларның статусын билгеләүче башка муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә күрсәтмәләр һәм боерыклар чыгаралар.

## 76 маддә. Муниципаль хокукый актларны әзерләү

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары район Башлыгы, район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин, шулай ук районның Контроль-хисап палатасы, районның Финанс-бюджет палатасы, районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан аларның алып бара торган мәсьәләләре буенча.

Прокурор үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү зарурилыгын билгеләп муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, юкка чыгару яки кабул итү турында проектлар һәм тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

2. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе, аларга теркәп бирелә торган документлар исемлеге һәм формасы район Советы Регламенты, район Башлыгы, район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

3. Башка муниципаль берәмлекләрнең муниципаль норматив хокукый актлары проектлары (алар муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне билгели яисә үзгәртә) эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысын бәяләргә мөмкин, түбәндәгеләрдән гайре:

1) җирле салымнар һәм җыемнар билгели, үзгәртә, туктатып тора, юкка чыгара торган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары норматив хокукый актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары норматив хокукый актлары проектлары;

3) гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне дә.

**77 маддә. Район Советының хокукый актлары**

1. Район Советы үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча, район территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиешле кагыйдәләр билгели торган карарлар, район Башлыгын отставкага җибәрү турында карар, район Советы регламенты, район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча башка карарлар, шулай ук аның компетенциясенә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав керткән башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

2. Район Советы карарлары район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә, законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан гайре.

3. Советның җирле салымнар һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгаруны, район бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан карарлары район Советы каравына бары тик район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән генә яки аның бәяләмәсе булса гына кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән бәяләмә район Башкарма комитетына карар проектын тәкъдим иткән көннән алып утыз көн эчендә район Советына тапшырыла.

4. Район Башлыгы тавышы район Советы депутаты тавышы буларак карар кабул иткәндә исәпкә алына.

5. Район Советы карарларына район башлыгы тарафыннан алар кабул ителгән

көннән алып өч көн эчендә кул куела һәм әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелә.

### 78 маддә. Район Башлыгының хокукый актлары

1. Район Башлыгы законнар, әлеге Устав һәм район Советы карарлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, шулай ук "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә әлеге Устав белән аның компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча да.

### 79 маддә. Район Башкарма комитетының хокукый актлары

1. Район башкарма комитеты җитәкчесе федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта, район Советы карарларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә район башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләре һәм районның җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләре буенча карарлар, шулай ук Башкарма комитетның район Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләрен чыгара.

### 80 маддә. Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Район Советы карарлары район башлыгы кул куйган көннән үз көченә керә, әгәр карарның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса.

Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Район Советының район Уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлары федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Район Башлыгының, район Башкарма комитетының, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары әгәр башкасы актларның үзләре тарафыннан билгеләнмәгән булса, аларны имзалаган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, гамәлгә куючы оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми бастырып чыгару дип районда таратыла торган вакытлы матбугатта аның тулы текстын беренче бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан (урнаштырылган) очракта аңа күләмле график һәм таблицалы кушымталар басмада китерелмәскә дә мөмкин.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары булырга тиеш: исеме (аталышы), аңа кул кую датасы (район Советы кабул иткән хокукый актлар өчен - шулай ук аның район Советы тарафыннан кабул ителү датасы), теркәлү номеры, хокукый актка кул куйган вазыйфаи затның (урындагы кешенең) аталышы.

5. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән һәр килешүдә аның реквизитлары булырга тиеш: исеме, аны имзалау датасы, килешүгә кул куйган вазыйфаи затларның исемнәре.

6. Район Советының район бюджеты турында, аның үтәлеше турында, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү, район Советы, район Башлыгы, район Башкарма комитеты кабул иткән башка норматив хокукый актлар турында карарлары имзаланган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш, мәгълүматларын тарату федераль закон белән чикләнгән муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән гайре.

7. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр аларны имзалаганнан соң җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

8. Җирле референдумны билгеләү, чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору, район Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау, район Башкарма комитеты җитәкчесен һәм аның урынбасарларын билгеләп кую һәм законнар нигезендә башка актлар турындагы норматив булмаган хокукый актлар шулай ук рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

9. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган органнар яисә район җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) мөмкин.

10. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

Муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" нда хокукый акт текстын веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру (бастырып чыгару): http://pravo.tatarstan.ru;

- хокукый акт текстын районның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган басма гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару яисә район территориясендә таратыла торган һәм район Советы карары белән билгеләнгән башка басма гаммәви мәгълүмат чаралары. Хокукый акт текстын башка басма гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы турында тамга булырга тиеш.

Муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү хокукый акт текстын веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында

районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.

11. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең реквизитлары күрсәтелә.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастырып чыгару түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда урнаштыру (бастырып чыгару): http://pravo.tatarstan.ru;

- җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын районның җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган басма гаммәви мәгълүмат чараларында яки район территориясендә таратыла торган һәм район Советы карары белән билгеләнгән башка басма гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү тексты басылып чыкканда, башка басма гаммәви мәгълүмат чараларында әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы хакында тамга булырга тиеш.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне игълан итү җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.

12. Муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) гаммәви мәгълүмат чарасының чыгу датасы күрсәтелергә тиеш.

13. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

## XIV бүлек. РАЙОННЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЕ

### 81 маддә. Районның икътисадый нигезе

1. Районның икътисадый нигезен районның муниципаль милкендәге мөлкәт, район бюджеты акчалары, шулай ук районның мөлкәти хокуклары тәшкил итә.

### 82 маддә. Районның муниципаль мөлкәте

1. Район милкендә булырга мөмкин:

1) әлеге Уставның 6 маддәсендә билгеләнгән районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Татарстан

Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук аларга “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлешендә каралган тәртиптә тапшырылган җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) район Советының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кагылмаган федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт (әлеге Уставның 7 маддәсе);

5) әлеге Уставның 8 маддәсе нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 17 маддәсендәге 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

2. Районның әлеге маддәнең 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракларда күрсәтелгән мөлкәтне кабат үзгәртергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнешен үзгәртү), я читләштерү тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә.

## 83 маддә. Районның муниципаль мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү

1. Районның җирле үзидарә органнары, әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрне чикләүне исәпкә алып, район исеменнән, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм район җирле үзидарә органнарының алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль мөлкәткә мөстәкыйль ия булалар, файдаланалар һәм алар белән эш итәләр.

2. Районның җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яисә даими файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә башка килешүләр ясарга, читләштерергә хокуклы.

3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль законнар нигезендә район җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнә. Муниципаль мөлкәттән файдаланудан керемнәр җирле бюджетка керә.

## 84 маддә. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре

1. Район федераль законнарда, әлеге Уставта һәм башка муниципаль норматив

хокукый актларда билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципальара җәмгыятьләр төзүдә катнаша ала. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. Районның җирле үзидарә органнары район исеменнән муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидияләп җавап бирәләр һәм аларны федераль законда билгеләнгән тәртиптә үтәүне тәэмин итәләр.

3. Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең максатларын, шартларын һәм эшчәнлек тәртибен билгелиләр, аларның уставларын раслыйлар, үз вазыйфасына билгеләп куялар һәм әлеге предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләрен вазыйфаларыннан азат итәләр, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында каралган тәртиптә аларның эшчәнлеге турында хисаплар тыңлыйлар.

### 85 маддә. Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре

1. Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, әгәр законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса, килешү нигезендә төзелә.

## XV бүлек. РАЙОННЫҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

### 86 маддә. Район бюджеты

1. Районның үз бюджеты бар.

2. Район бюджеты район Советының норматив хокукый акты рәвешендә эшләнә һәм раслана.

3. Район бюджетында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән керемнәр һәм районның җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән субвенцияләр, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр исәбеннән район бюджетының тиешле чыгымнары. аерым карала.

4. Район җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең федераль органнарына һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына район бюджеты үтәлеше турында хисаплар тапшыралар.

**87 маддә. Районда бюджет процессы**

1. Район бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту районның җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла. Район бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

2. Район бюджеты проекты, район Советының район бюджетын раслау турындагы карары, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, квартал саен район бюджетын үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны күрсәтеп, аларның саны турында мәгълүматлар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

3. Район Советы район бюджеты керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм район бюджеты турында карар кертелгәннән соң кабул ителгән район Советының норматив хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.

4. Район бюджеты проекты район Советының муниципаль хокукый акты нигезендә өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен үтәгән килеш кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә төзелә.

6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документлар;

Россия Федерациясе бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак вакытлы чорга бюджет фаразлары (бюджет фаразлары проекты һәм бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карарда бюджетның төп сыйфатламалары булырга тиеш, аларга бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы (артыклыгы) керә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан

Республикасы законнары, район Советының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләр (бюджет турындагы карардан гайре).

8. Район Советының район бюджеты турындагы карарында шәһәр, авыл җирлекләре бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары булырга тиеш шул очракта, әгәр алар Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнмәгән булса.

9. Район бюджеты турындагы карар белән составы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары, район Советының муниципаль хокукый актлары нигезендә билгеләнә торган күрсәткечләр раслана.

10. Район бюджеты турындагы карар белән раслана:

район бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеге;

район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеге;

чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан маддщлщре, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча бюджет ассигнованиеләрен яки чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан маддәләре (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләр), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча (яисә) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләренең максатчан маддәләре (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, район Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән очракларда бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү дә;

чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

чираттагы финанс елында һәм план чорында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына башка бюджетлардан алына торган һәм (яисә) бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

Чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына район бюджеты расланган очракта шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган район бюджеты чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елына бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган район бюджеты чыгымнарын исәпкә алмыйча);

Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты кытлыгын

финанслау чыганаклары;

Чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп;

район бюджетының Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, район Советының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләре.

11. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карар проекты расланган бюджетның планлы чор параметрларын үзгәртү һәм аларга бюджет проектының план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән раслана.

12. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта район Советына тапшырыла:

чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

агымдагы финанс елының узган чорында районның социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында районның социаль-икътисади үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

чираттагы финанс елына һәм план чорына районның социаль-икътисадый үсеше фаразы;

чираттагы финанс елына һәм план чорына районның берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы (артыклыгы)) фаразлары яисә урта сроклы финанс планы керемнәрнең гомуми күләме;

район бюджеты проектына аңлатма язуы;

бюджетара трансфертларны бүлүнең методикалары (методикалары проектлары) һәм исәп-хисаплары;

чираттагы финанс елы һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге;

агымдагы финанс елына район бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләү;

күрсәтелгән бюджет сметаларына карата район Советы, районның контроль-хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата район финанс-бюджет палатасы белән каршылыклар барлыкка килгән очракта, күрсәтелә;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Уставта билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

Район бюджеты турындагы карар белән расланган очракта, муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү район бюджеты турындагы карар проектына муниципаль программалар паспортлары тапшырыла (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары).

Район бюджеты турында карар проектында бюджет чыгымнары

классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү кушымтасы булмаган очракта бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлгәләгән кушымта район бюджеты турындагы карар проектына аңлатма язуына кушымталар составына кертелә.

13. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын төзү районның финанс-бюджет палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар, алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Район башкарма комитеты чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карар проектын агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча район Советы каравына кертә.

15. Район бюджеты турындагы карар проектын карау һәм аны район Советының муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнгән раслау тәртибе чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан район бюджеты турында карар үз көченә керүне күздә тотарга тиеш, шулай ук күрсәтелгән карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 маддәсе нигезендә күрсәткечләрне һәм сыйфатламаларны раслауны да.

16. Район бюджеты турындагы карар 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) район бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса, финанс елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Район бюджеты турындагы карар билгеләнгән тәртиптә кул куйганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

17. Районның җирле үзидарә органнары район бюджетының баланслылыгын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, муниципаль бурыч кытлыгы, күләме һәм структурасы, районның бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы законнарының һәм федераль законнарның үтәлешен тәэмин итәләр.

18. Район бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә төзелә (формалаштырыла).

19. Район бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган рәвешләрдә гамәлгә ашырыла.

20. Дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга район бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру рөхсәт ителми, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан гайре.

21. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 88 маддә. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар,

эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 89 маддә. Район гражданнарының үзара салым акчалары

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәннән гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салым тәртибендә түләүләр күләме абсолют зурлыкта районның барлык халкы өчен тигез дип билгеләнә, саны район халкының гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш булган һәм алар өчен түләүләр күләме кимергә мөмкин булган район кешеләренең аерым категорияләрдән гайре.

2. Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер мәртәбә бирелә торган түләүләрен кертү һәм алардан файдалану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

## 90 маддә. Районның муниципаль әҗәткә алулары (муниципаль бурыч)

1. Муниципаль эчке бурычка алулар астында муниципаль берәмлек исеменнән җирле бюджетка муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә заем акчаларын җәлеп итү карала, алар буенча Россия Федерациясе валютасында белдерелгән заемчы буларак муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.

2. Муниципаль әҗәт алуларны гамәлгә ашыру хокукы район исеменнән Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә район Башкарма комитетына карый.

## 91 маддә. Районның җирле бюджетын үтәү

1. Районның җирле бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Район бюджеты касса бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомство буйсынуы нигезендә башкарыла.

3. Район бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, район бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Район бюджетын үтәү районның җыелма бюджет язмасы һәм районның касса планы нигезендә оештырыла.

## 92 маддә. Бюджет хисабы. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап

1. Районның бюджет хисабы еллык булып тора.

2. Районның бюджет хисабы районның финанс-бюджет палатасы тарафыннан

бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә төзелә һәм район Башкарма комитетына тапшырыла.

3. Район бюджетының үтәлеше турында еллык хисап район Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Районның финанс-бюджет палатасы муниципаль районның берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бюджет хисабы тапшыра.

5. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап, аны район Советында караганчы, тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисабын тышкы тикшерүне һәм район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

Район бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү районның контроль-хисап палатасы тарафыннан әлеге Уставта һәм район Советының муниципаль норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла. Район составына керүче җирлекнең вәкиллекле органы мөрәҗәгате буенча җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү районның контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Район Башкарма комитеты аңа агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча бәяләмә әзерләү өчен район бюджетының үтәлеше турында хисап бирә. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бюджет акчалары баш бүлүчеләрнең еллык бюджет хисабының еллык бюджет тикшерүе күрсәткечләре нигезендә 1 айдан артмаган срокта үткәрелә.

7. Ел саен, агымдагы финанс елының 1 маеннан да соңга калмыйча, район Башкарма комитеты район Советына хисап финанс елы өчен район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап тапшыра район Советының хисап финанс елында район бюджеты үтәлеше турында карар проекты, район бюджеты үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгы, районның берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында бюджет хисаплылыгы һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган башка документлар турында кушымтасы белән.

8. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча район Советы район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Район Советы тарафыннан район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап кире кагылган очракта, ул мәгълүматларны дөрес булмаган яки тулы булмаган чагылдыру фактларын бетерү һәм бер айдан да артмаган срокта кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

9. Район бюджеты үтәлеше турындагы карар белән район бюджеты үтәлеше турында хисап раслана, анда район бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм кытлыгының (артыклыгының) гомуми күләме күрсәтелә.

Район Советының хисап финанс елында район бюджеты үтәлеше турындагы карарына аерым кушымталар булып түбәндәге күрсәткечләр раслана:

бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары буенча район бюджеты керемнәре;

район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча район бюджеты чыгымнары;

бюджетлар чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча район бюджеты чыгымнары;

бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

Район бюджеты үтәлеше турындагы карар белән шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, район бюджеты үтәлеше турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы законы, район Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән башка күрсәткечләр раслана.

### 93 маддә. Муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле хокукый актларның нигезләмәләрен үтәүне, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен, гавами норматив йөкләмәләрне һәм физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан башка түләүләр буенча йөкләмәләрне билгели торган хокукый актларны җайга сала торган актлар, шулай ук бюджеттан акча бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, алдан һәм аннан соңгы финанс контроленә бүленә.

2. Тышкы муниципаль финанс контроле районның Контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Эчке муниципаль финанс контроле – район Башкарма комитеты органнары булып торган муниципаль финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге.

4. Алдан контроль район бюджетын үтәү барышында бюджет бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.

5. Алга таба контроль район бюджетының үтәлеше нәтиҗәләре буенча, аның үтәлешенең законлылыгын, исәп-хисапның дөреслеген билгеләү максатыннан башкарыла.

## XVI бүлек. РАЙОН УСТАВЫН КАБУЛ ИТҮ. ӘЛЕГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ

### 94 маддә. Район уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты район Советы каравына район Башлыгы, район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан. кертелергә мөмкин.

2. Район уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен район Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга

мөмкин.

3. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты, аларны карау көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, район Советы тарафыннан күрсәтелгән Устав проекты, район Советының күрсәтелгән карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибенең, шулай ук гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибенең бер үк вакытта басылып чыгуы (халыкка җиткерелүе) белән рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның район буенча фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми шул очракта, әгәр Район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезләмәләрен әлеге Уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелсә.

4. Район Уставы проекты, район Советының әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары буенча аларны район Советы утырышында карау алдыннан әлеге Устав нигезендә гавами тыңлаулар уздырыла, әлеге Уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан гайре.

### 95 маддә. Район Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Район уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын карау район Советы регламенты нигезендә кимендә ике укылышта район Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Район уставы проекты әлеге Уставка беренче укылышта үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты кабул ителгәннән соң күрсәтелгән проект төзәтмәләр кертү өчен район Башлыгы тарафыннан хокукый иҗат инициативасы хокукына ия субъектларга җибәрелә.

3. Устав района, решение Совета района о внесении изменений и дополнений в Устав принимаются большинством в две трети голосов от установленной численности депутатов Совета района. Район уставы, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары район Советы депутатларының билгеләнгән санынна күпчелек булган өчтән ике өлешенең тавышы кабул ителә.

4. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) район Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы район Башлыгының берүзенең кулы куелган район Советы карары белән;

2) район Советы тарафыннан кабул ителгән һәм район Башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге хокукый актта район Советының аны кабул итү турындагы карары реквизитлары куела. Район

Советының мондый карарына район Уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында күчеш нигезләмәләрен һәм (яисә) нормаларын кертү рөхсәт ителми.

5. Район Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль закон, Татарстан Республикасы законы белән күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, район уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы законы үз көченә керү датасын, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проектын гавами тыңлауларда рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аның буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алып фикер алышу зарурлыгы исәпкә алып билгеләнә, район Советы утырышларының чиратлылыгы, район Советының мондый карарын дәүләт теркәвенә алу һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) сроклары һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.

6. Район Уставын яңа редакциядә район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта яңа Устав кабул ителә, ә элек районның гамәлдәге Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар яңа Устав үз көченә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.

**96 маддә. Район Уставының, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карарның үз көченә керү тәртибе**

1. Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары кабул ителгәннән соң район Башлыгы тарафыннан федераль башкарма хакимият органының кануннарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендәге вәкаләтле органының территориаль органына җибәрелә.

2. Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының "Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар" (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басмасы сыйфатында теркәлү: Эл. N ФС77-72471, 05.03.2018) порталында рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керәләр. Район Башлыгы район Уставын, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарны муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставы турындагы мәгълүматларны, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый актны "Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында" 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 маддәсендәге 6 өлешендә каралган Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт

реестрына кертү турында хәбәрнамә кергән көннән башлап җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.

3. Район Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (район Уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан тыш, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының вәкаләтләрен, вәкаләтләре срогын үзгәртү, сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан гайре) күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка кул куйган район Башлыгының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

4. Уставка кертелгән һәм районның контроль-хисап органын булдыруны күздә тоткан үзгәрешләр һәм өстәмәләр әлеге маддәнең 2 өлешендә каралган тәртиптә үз көченә керә.